Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

03

март 2020

ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

«Яңарыш» фондының яшь хәйриячеләре

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең мирас 12 +
03(315)
март 2020

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Бу санны әзерләүдә ярдәме өчен, ТР Дәүләт Киңәшчесенең ярдәмчесе **Нурсөя Шәйдуллина**га, «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» директоры **Рамил Җиһаншин**га, «Зөя утрау-каласы» музей-тыюлыгы директоры **Артём Силкин**га рәхмәтебезне җиткерәбез.

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм битка салучы
Диләрә Наурузова
(843) 222-09-83 (17-93)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энже Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный,
литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)

Тышлыкның 1 нче битендә –
«Яңарыш» фондының иң яшь хәйриячеләре – Ралина, Кәрим, Самир, Камил һәм Әскәр Нугаевлар.
Андрей Титов фотосы

128

Эчтәлек

2 Татарстан Республикасы Президенты Указы
3 «Яңарыш» фондына – 10 ел. *М.Шәймиев*

10 **Болгар**

12 Тарихи белешмә
13 Борынгы Болгарда. *Р.Вәлиев*
16 Таныш ташлар тавышы...
18 Җәмигъ мәчете
20 «Шәһре Болгарның бәгъзе асаре»
22 Олы манара
24 Кара пулат
26 Шәһри Болгар бәетләре
28 Кече манара
31 Сызлаулы хәтерне яңарту. *З.Мансуров*
32 Ханнар төрбәсе
34 Көнчыгыш төрбә
36 Төньяк төрбә
38 Ак пулат

50

84

114

42 Хан сарае
44 Көнчыгыш пулат
46 Чүлмәк яндыру мичләре. *Ф.Хуҗин*
48 Идел буе Болгар дәүләтенең 922 елда исламны дәүләт дине буларак кабул итүе хөрмәтенә истәлек билгесе
50 Ак мәчет
52 Болгар цивилизациясе музее
54 Икмәк музее
56 Сәхабәләргә һәйкәл
57 Айдар хан һәм сәхабәләр *(Риваять)*
58 Табиб йорты
60 Болгарларда медицина. *Г.Дәүләтшин*
62 Төрки-татар язма мирасы күргәзмәсе
64 Габдрахман сәхабә коесы
65 Абдулла Алиш музее
66 Елга вокзалы
68 Изге Болгар җыены
69 Хәтер. *Х.Әюп*

68

70 Зөя утрау-каласы

72 Тарихи белешмә
74 Татар мәгърифәтчеләре Зөя утрау-каласы турында
76 Җир астында – чал тарих
78 Татар бистәсе. *А.Ситдыйков*
82 Троица чиркәве
84 Успение соборы
86 Успение монастыре
88 Никола Чудотворец чиркәве
90 Татар мәгърифәтчеләре Зөя утрау-каласы турында
92 Сергий чиркәве
94 Константин һәм Елена чиркәве
96 «Барлык Кайгылылар Шатлыгы» соборы
98 Казна корылмалары комплексы
100 Зөя утрау-каласы тарихы музее
102 «Әкият» балалар ял үзәге
102 Солтан патша турында әкият. *А.Пушкин*
104 Гражданнар сугышы музее
106 Сәяси репрессия корбаннары истәлегенә мемориал
107 Бу соңгы таңы аның. *Х.Туфан*
108 Ат утары биналары комплексы
110 Каменев йорты
111 Өе барның көе бар
112 Елга вокзалы
114 Гасырларны кичкән бәйрәмнәр
116 Татарстан Республикасы Президенты Указы

117 Болгар ислам академиясе
120 Казан Мәрьям ана иконасы соборы

123 Ихлас күңелдән

128 Адымнар

Заказ №А-414. Тираж – 4956 данә.
Формат 70x108 1/16
Басарга кул куелды: 26.02.2020.
Чыгу көне: 03.03.2020.
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Бәясе ирекле.

Бу сан «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторлцарның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Валерий Павлов, Артём Силкин, Андрей Богданов, Гөлнара Сагиева, Максим Дмитриев, Ленар Гобәйдуллин төшергән, https://tatmitropolia.ru/, ТР Президенты Матбугат үзәге архивыннан, «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» һәм «Зөя утрау-каласы» музей-тыюлыгыннан, Татарстан Милли музееннан алынган фотолар файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

УКАЗ
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ

Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фондын төзү турында

Болгар тарих-архитектура музей-тыюлыгын, «Зөя утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музееи, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан башка тарихи һәм мәдәни истәлекләрне торгызуга һәм үстерүгә, Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының тарихи, мәдәни һәм рухи традицияләрен, татарларның милли-мәдәни үзенчәлеген һәм традицияләрен саклап калу һәм үстерүгә булышлыкны оештыру максатларында, шулай ук моның өчен кирәкле финанс ресурсларын җәлеп итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан, җирле үзидарә органнарыннан, җәмәгать берләшмәләреннән һәм гражданнардан кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, җирле үзидарә органнарының, җәмәгать оешмаларының һәм гражданнарның Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан тарихи һәм мәдәни истәлекләрне торгызуга юнәлтелгән эшне көчәйтү буенча инициативасын якларга.

2. Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фондын (алга таба – Фонд) коммерциячел булмаган оешма рәвешендә оештырырга.

3. Фондның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт дип билгеләргә:

Болгар тарих-архитектура музей-тыюлыгын саклап калуга, торгызуга, реставрацияләүгә, «Зөя утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музееи, тарихи, археологик, архитектура, шәһәр төзелеше, сәнгати, эстетик, этнологик яки антропологик, социаль мәдәният күзлегеннән чыгып караганда кыйммәткә ия дип табылган башка мәдәни байлыкларны архитектура-художество ягыннан торгызуга булышлык күрсәтү;

мәдәни мирас объектларын популярлаштыру;

Татарстан Республикасының фәнни, мәдәни, интеллектуаль потенциалын булдыруга булышлык күрсәтү.

4. Акчалата һәм башка формаларда Фонд милеген формалаштыру чыганакларын түбәндәгеләр тәшкил итә дип билгеләргә:

Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан акчалар;

барлык милек төрләрендәге оешмалар һәм предприятиеләрнең һәм физик затларның ихтыяри кертемнәре һәм иганәләре;

чит ил эшмәкәрләренең, юридик һәм физик затларның ихтыяри кертемнәре;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китереп, башка чыганаклар.

5. Беренче чиратта финансланучы Тарихи һәм мәдәни объектлар исемлеген (кушымта итеп бирелә) расларга.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

ике атна эчендә «Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фонды» коммерциячел булмаган оешмасы уставы проектын раслауга тәкъдим итәргә;

2010 елдан алып һәр ел саен Фондның уставында каралган эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан тарихи һәм мәдәни истәлекләрне торгызу буенча программаны үтәү өчен кирәкле акчаларны Татарстан Республикасы бюджетында карарга;

түбәндәгеләр буенча тәкъдимнәр кертергә:

Фондның эшчәнлегенә күзәтчелек итү органы буларак, аның попечительләр советы составы;

Фондны Казан шәһәрендә урнаштыру;

Фондка учредительнең мөлкәти кертеме сыйфатында тапшырыла торган Татарстан Республикасы мөлкәте составы.

7. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты **М.Ш. Шәймиев**

Казан, Кремль
2010 ел, 17 февраль
№ ПУ-71



МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ,
Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе,
«Яңарыш» Республика фондының Попечительләр Советы Рәисе,
ЮНЕСКОның мәдәниятара диалог буенча Махсус илчесе

«ЯҢАРЫШ» фондына – 10 ел

Барыбыз да яхшы хәтерлибез: 2005 елда Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итәр алдыннан Казан Кремле биләмәсендә тарихи Кол Шәриф мәчетен тергездек һәм Благовещение соборын яңарттык. Ул чакта бу биналарны торгызу өчен фонд оештырылды, анда республиканың зур һәм кече предприятиеләре, бөтен халкы катнашты. 1996 елда иген уңды, авыл кешеләре үз җыеннарында һәр гектардан берәр центнер ашлык сатып, акчасын Кол Шәриф мәчете төзелеше һәм Благовещение соборын торгызу исәбенә күчерергә карар итте. Һич күпертмичә әйтәм – бу вакыйга көчле рухи яңарыш башлануын дәлилләде. Алга таба ул 2010 елда без оештырган «Яңарыш» фондының Болгар һәм Зөя шәһәрләрендәге тарихи-мәдәни истәлекләрне тергезү эшчәнлегенә бөтен халык ярдәме рәвешендә чагылды. Биш елдан соң, замана таләбе буенча, эшчәнлегебез киңәйде, яңа проектлар барлыкка килде: бер үк вакытта без Болгар ислам академиясен төзүгә һәм Казан Мәрьям ана иконасы соборын тергезүгә тотындык.

Болгарда һәм Зөя утравында киң колачлы эшләр башлап, борынгы ядкәрләрне тергезгәндә, кирәкле инфраструктура булдырганда без, әлбәттә, җәмгыятьтә рухи яңарышның катлаулы, иҗади, фәнни-танып белү процессын башлап җибәрүебезне аңлый идек. Без бу еллар дәвамында төзеп, реставрация ясап, тарихны, археологияне өйрәнеп кенә калмадык, ата-бабаларыбыз зирәклегенә, исламның һәм православиенең рухи мәгънәсенә дә төшенә бардык. Шунысы бик мөһим: барысы да халыкара дәрәҗәдә, тиешле фәнни нигездә һәм ЮНЕСКОның барлык таләпләренә тәңгәл итеп эшләнде. Нәтиҗәдә, Болгар һәм Зөя шәһәрләре ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелде, бу исә – аларның күренекле универсаль хәзинә булуын бөтен дөнья таныды дигән сүз.

Без борынгы Болгар шәһәрендә һәм Зөя утрау-каласында тарихи ядкәрләрне тергезү буенча проектны гамәлләштерүнең бөтен халык эшенә әверелүе белән горурланабыз. Ниятең халык күңеленә хуш килә икән, эш тә җиңелрәк бара. Бу киң колачлы проектның уңышын ил җитәкчелегенең, Россия Президенты Владимир Владимирович Путинның һәм Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановның, тигез өлешләрдә акча биргән Россия һәм Татарстан хөкүмәтләренең, республиканың күпмилләтле халкының, җәмәгатьчелекнең, эшкуарларның һәм үз илебезнең, чит илләрнең йөз меңләгән хәйриячеләренең ярдәме тәэмин итте. Безнең фондның хәйриячесе булып, шушы елларда безгә ихлас күңелдән ярдәм иткән барлык кешеләргә рәхмәт сүзләре җиткерәм. Безнең проектта катнашканда, һәрберебезнең күңел матурлыгы ачылды, һәммәбез игелеклерәк булырга тырышты, яхшы якка үзгәрде. Барыгызга да, барысы өчен дә зур рәхмәт!

Мәгълүм ки, узган ел без Болгар белән Зөя шәһәрләрен тергезү буенча проектны төгәлләдек һәм аларны, туристлык эшен оештыру һәм дөрес идарә итү өчен, тиешле министрлыклар һәм оешмалар карамагына тапшырдык. Хәзер бу истәлекле урыннарга ел саен бер миллионнан артык турист һәм зиярәт кылучы килә.

2015 елның 4 ноябрендә – Халыклар бердәмлеге көнендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның «Болгар ислам академиясен төзү һәм Казан Мәрьям ана иконасы соборын торгызу турында» Указга кул куюын исегезгә төшерү урынлы булыр дип уйлыйм. Әлеге гамәл элеккеге тарихи мирасны торгызуга гына түгел, хәзерге заманда дөньяның күп дәүләтләре җитәкчеләрен һәм гражданнарын борчый торган проблемаларны хәл итүгә дә юнәлдерелгән иде. Тупланган тәҗрибәне исәпкә алып, бу эшне оештыру «Яңарыш» Республика фондына йөкләнде.

Сез беләсез, Болгар ислам академиясен бер ел эчендә төзеп бетердек һәм ул хәзерге вакытта күренекле татар дин галимнәре үрнәгендә югары дәрәҗәдә әзерлекле, тирән белемле, абруйлы кешеләрне инандыру, экстремистлык агымнарына каршы тору сәләтенә ия заманча дин эшлеклеләре-галимнәр укыту-тәрбияләүдә уңышлы тәҗрибә туплап килә. Академия эшчәнлеген Россия Президенты Владимир Путинның тулысынча хуплавы зур әһәмияткә ия, аның Попечительләр советын Россия Президенты администрациясе башлыгының беренче урынбасары Сергей Кириенко җитәкли.

Бөтен христиан дөньясында олы ихтирамга ия Казан Мәрьям ана иконасы табылган урында собор тергезү – Россия өчен генә түгел, бөтен дөнья өчен дә әһәмиятле вакыйга. Хәзерге вакытта төзелеш буенча төп эшләр ахырга якынлашып килә, төп көчләр Өске храмның иконостасын ясауга һәм эчке ягын бизәүгә юнәлдерелә. Аскы өлештәге уникаль Мәгарә храмы нигездә торгызылды һәм аны изгеләндерүгә әзерлек эшләре бара.

«Яңарыш» Республика фондының төп казанышы шунда: тарихи мирасны саклауның мөһимлеге турында биргән сигналыбыз республиканың һәм илнең киң җәмәгатьчелегенә барып җитте. Хәзер күп кенә кешеләр үзләренең кече Ватаннары тарихына игътибар бирә башлады. Без барыбыз да аңлый башладык: тергезелгән ядкәрләр күбәйгән саен, җиребездә рухи байлык арта бара.

Яшь буынга тергезелгән мирасны, шуның белән бергә иман, гореф-гадәтләр һәм эчке культура кебек рухи хәзинәләребезне тапшырганда, без аларның бу мирасны киләчәк хакына саклый алырга сәләтле булуына инанырга тиеш. Аларны үз мирасын өйрәнүчеләр һәм кадерен белүчеләр, башкалар мирасын ихтирам итүчеләр, телләрнең һәм мәдәниятләрнең күптөрлелеген кабул итүчеләр итеп тәрбияләү һәм аларга күп яклы белем бирү, гомумән әйткәндә, аларны хәзерге ачык һәм тиз үзгәрүчән дөньяда көндәшлеккә сәләтле итеп тәрбияләү гаять мөһим.

Нәкъ менә шуның өчен, «Яңарыш» Республика фонды бер ел элек, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән бергәләп, Казан федераль университеты катнашында, белем бирүнең уникаль проектын гамәлгә ашыруга: күп телдә – рус, татар, инглиз телләрендә – белем бирү комплекслары булдыруга кереште.

Һәрбер комплекс балалар бакчаларын, башлангыч һәм урта мәктәпләрне үз эченә ала. Шәһәр читендәге ике үзәк өстәмә белем бирү юнәлешендә эшләячәк. Башлангыч проектта без күп телдә белем бирүче алты комплекс булдыруны күздә тотабыз: икесе – Казанда, калганнары – Алабугада, Чаллыда, Түбән Камада һәм Әлмәттә. Беренче ике комплекс укучыларны Казанда һәм Алабугада 2020 елның 1 сентябрендә үк кабул итәчәк.

Барлык мәктәпләрне дә «Адымнар – белемгә һәм килешүгә юл» дигән исем берләштерә. Бу исә – Татарстанча яшәүнең, дуслыкта һәм татулыкта иҗтиһад итүнең тагын бер күркәм чагылышы. Без моны булдырабыз! Мы можем! We can!

Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя утрау-каласы белән таныша. 2012 елның 28 августы

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ,
Татарстан Республикасы Президенты:

«Татарстан – аерым миссиягә ия төбәк. Бездә милләтара һәм динара татулыкның күп гасырлык тәҗрибәсе саклана, ул республиканың тотрыклыгы һәм иминлеге нигезе, гөрләп алга баруының куәтле факторы булып тора. Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев тә – миссия кешесе. Ул оештырган «Яңарыш» фондының эшчәнлеге – үткән белән киләчәк арасындагы күпер. Бу күпер буйлап ун еллык озын юл узгач, без ислам һәм православие мәдәниятләренең тергезелгән һәм ЮНЕСКОның Бөтендөнья исемлегенә кертелгән ядкәрләре булган башка республиканы күрәбез».

ИРИНА БОКОВА,
ЮНЕСКО Генераль директоры (2010-2017 еллар):

«Мин үзем Болгариядән, безнең тарихи тамырларыбыз охшаш. Болгарны күргәннән соң күңелемдә көчле тәэсирләр калды. Зур эш башкарылган. Бирегә килүчеләрнең күп булуы шатландыра. Үз тарихыңны белү һәм ихтирам итү мөһим. Ә иң мөһиме – аны саклау.

Зөя утрау-каласы – православие дине өчен әһәмиятле тарихи урын. Утрау-калада урнашкан гыйбадәтханәләр үзләрен төзегән уңганнарның осталыгын һәм талантын дәлилләп тора».


United Nations
Educational, Scientific and
Cultural Organization

World Heritage
Convention

CONVENTION CONCERNING
THE PROTECTION OF
THE WORLD CULTURAL
AND NATURAL HERITAGE

The World Heritage Committee
has inscribed

Bolgar Historical and Archaeological Complex

on the World Heritage List

Inscription on this List confirms the outstanding
universal value of a cultural or
natural property which requires protection for
the benefit of all humanity

DATE OF INSCRIPTION
25 June 2014

Irina Bokova
DIRECTOR-GENERAL
OF UNESCO

2014 елның 23 июнендә Катар башкаласы Доһада Болгар тарих-археология комплексы Бөтендөнья мирас комитеты утырышында ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелде.

2017 елның 9 июлендә Польшаның Краков шәһәрендә Зөя утрау-каласындагы Успение соборы һәм монастыре ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелде.



United Nations
Educational, Scientific and
Cultural Organization

World Heritage
Convention

CONVENTION CONCERNING
THE PROTECTION OF
THE WORLD CULTURAL
AND NATURAL HERITAGE

*The World Heritage Committee
has inscribed*

*Assumption Cathedral and Monastery
of the town-island of Sviyazhsk*

on the World Heritage List

*Inscription on this List confirms the outstanding
universal value of a cultural or
natural property which requires protection for
the benefit of all humanity*

DATE OF INSCRIPTION
12 July 2017

DIRECTOR-GENERAL
OF UNESCO

Болгар

Тарихи белешмә

Безнең эраның VII гасырында ук халыкларның көнчыгыштан көнбатышка бөек күчеше нәтиҗәсендә борынгы төрки кабиләләрнең Азов буенда Бөек Болгар дәүләте төзүләре мәгълүм, аның башында исеме риваятьләрдә калган Кубрат хан торган. Бу держава таркалгач, төрки телле кабиләләрнең бер өлеше Европаның төрле төбәкләренә таралган.

VIII-IX гасырларда болгар кабиләләренең башка бер төркеме Азов буеннан Урта Иделгә күчеп, Идел буе Болгар дәүләте төзегән.

Мөселман шәһәр мәдәниятенең югары дәрәҗәсе мәгърифәтчеләрнең, укытучыларның, галимнәрнең актив эшчәнлеге өчен шартлар тудырган. Бөек Болгарда күпсанлы ислам уку йортлары гыйлемгә өйрәткән, мәчетләрдә мәшһүр дин белгечләре укыткан, фәлсәфәчеләр һәм фикер ияләре фәнни хезмәтләр, ә шагыйрьләр үзләренең күренекле әсәрләрен язган. Дөнья мәдәниятенең танылган җәүһәре – «Кыйссаи Йосыф» поэмасы авторы Кол Гали биредә яшәп иҗат иткән. Болгар галимнәренең медицина, астрономия, математика һәм башка фәннәр буенча хезмәтләре бүген дә Русиядән ерак илләрдә билгеле.

922 елда биредә болгарлар – хәзерге Казан татарларының ата-бабалары – рәсми рәвештә ислам динен кабул иткәннәр. X гасырда Болгарда яңа дәүләтнең символы – акча-тәңкә сугылган.

1236 елда Болгар монголлар тарафыннан яулап алынган һәм яндырылган. XIII гасыр уртасында яңадан аякка баскан.

Урдадагы туктаусыз феодаль чуалышлар Болгарны әкренләп һәлакәткә алып барган. Шуларның берсе – Аксак Тимернең 1361 елда Болгарга һөҗүме, ушкуйникларның һәм рус кенәзләренең XIV гасыр ахыры-XV гасыр башындагы һөҗүмнәре һәм, ниһаять, 1431 елда бөек кенәз Василий II тарафыннан җибәрелгән кенәз Федор Пестрый җитәкчелегендәге Мәскәү гаскәрләре һөҗүме шәһәрне һәлакәткә дучар иткән.

П.С.Паллас (1741-1811) рәсеме. 1768 ел



«Кара пулат». П.С.Паллас рәсеме. 1768 ел

Борынгы Болгарда

Разил Вәлиев

Болгар җире, Бөек Болгар иле...
Тарихка мин саклыйм зур үпкә.
Бабамнарның мәгърур җаны кебек
Күтәрелә тургай биеккә.

Басу буйлап берәү җырлап килә,
Чал тарихтан килә, диярсең.
Барысы да мең ел элеккедәй...
Аргамаклар чаба иярсез.

Барысы да мең ел элеккедәй:
Ай-кояшы, зәңгәр күге дә...
Бөек илдән чүлмәк ватыклары
Бүләк булып калган бүгенгә.

Бөтен нәрсә монда якын миңа,
Әйтерсең, мин әнкәм куйнында.
Бөтен нәрсә монда Болгарымның
Оныклары кебек тоела.

Хәрабәләр, ташлар арасында
Башын иеп тора кылганнар...
Бабайларның сүзен сөйләр өчен
Тик кылганнар гына калганнар.

...Болгар иле – бабамнарның иле,
Тургай моңы – минем моңнарым.
Мин тургайны түгел, бүген гүя
Бабамнарның җырын тыңладым.

П.С.Паллас рәсеме. 1768 ел

Петр Великийның Болгар хәрабәләрен килеп каравы

1722 нче елда Болгар шәһәренең хәрабәләрен император Петр Великий килеп караган. Петр шунда Олуг мәсҗид манарасына менеп караган, шуның өстен тимер кыршау белән беркетергә кушкан. 49 данә кабер ташларын русчага тәрҗемә кылырга әмер иткән, шуларның кырык алтысы мөселманча язылган, өчесе әрмәнчә икән, мөселманча язылганнарын Йосыф Ишбулатов дигән кемсә тәрҗемә кылган, әрмәнчәләрен – Иван Васильев. Мөселманчаларының 22се һиҗрәттән 622 нче елда, калганнары 619дан 742гә кадәр куелганнар икән. Әрмән язулары 557, 849, 986 нчы елларда куелган булганнар, берсе 1268 нче елда куелган.



Ф.Х.Эрдман (1778-1846) рәсеме. 1819 ел

Екатерина Икенченең Болгар шәһәре урыннарын килеп каравы

Казаннан Әстерханга узган вакытта Екатерина Икенче (Әби патша) 1767 нче елда Болгар хәрабәләрен кереп караган. Шуннан Панинга хат язган:

«Идел буена чыгып, Болгар хәрабәсен карадык, Аксак Тимер кырган биналарның калганнарын күрдем, ике терек манарасы бик биек, татарлар бу урынны бик хөрмәтлиләр». Бер мөтәгассыйб Казан архиерее Лука, вафат булган императрица Елизавета Петровна заманында, моңа хөсетләнеп, бу биналарны ваттырган, ташларыннан погреблар салган, монастырь астына салдырган, ташлардан чиркәү салган. Гәрчә Петр Великийның «Бу асаре гатыйкаларны ватмаска, ярылган манараларны тимер кыршау белән беркетергә» дигән указы булса да.

Гайнетдин Әхмәровның «Болгар тарихы» китабыннан. 1909 ел

Таныш ташлар тавышы...

Болгар

Кем дә кем ташларны җансыз дип атар икән?
Кем дә кем ташларны хәтерсез дияр?
Бик самими, беркатлы кеше булыр ул.
Ташлар хәтерли генәме соң?! Алар тоя, тыңлый, сөйли дә әле.
Ишетә белсәң, билгеле.
Аларның мәгърур тынлыгы да биниһая мәгънәгә ия.

Шәһри Болгар истәлекләренең беренче тулы тасвирламасы 1712 елга карый. Успение монастыре корылган чор бу. Дьяк Михайлов шул вакытта таш ядкәрләрнең исемлеген төзи...

Ул ядкәрләрнең кайберсен без бүген Успение чиркәвенең нигезендә дә күрә алабыз...

Ун елдан соң Иделне буйлаган Петр I Болгарда туктала һәм, күккә ашкан манараларга күз тегеп сокланганнан соң, биредәге таш корылмаларның һәммәсен дә саклау чарасын күрергә куша.

Шәһәрлектә даими тикшерену эшләре 1938 елда А.П.Смирнов җитәкчелегендә башлана. Бу хәл Изге Болгарның һәр чорын, аның озын гомеренең һәр елын, көнен, йөрәк тибеше ешлыгын, сулыш тигезлеген өйрәнү өчен зур мөмкинлекләр ача.

Археологлар Идел буе Болгар дәүләтендә металл эшкәртү, зәркәнчелек, күн, чүлмәк ясау һәм башка һөнәрләрнең алга китүен дәлилләгән меңнәрчә табылдыкларга юлыга. Болгарның күн эшләнмәләре аеруча киң таралган. Көнчыгышта, Урта Азиядә, Европа илләрендә югары сыйфатлы йомшак күннең әлегәчә «болгари» дип йөртелүче төре бар.

Ташлар – мәңгелек алдында хәрәкәтсез калган мосафирлар...

Алар безгә бүген борынгы ата-бабаларыбызның сәламен тапшыра.

Безнең сәламне дә оныкларыбызга тапшырырга язсын.

Ялтыравык йөгертелгән савытлар

Сфероконуслар

Җәмигъ мәчете

Болгар

Борынгы бер бәеттә менә мондый юллар бар:
«*Шәһри Болгар мәсҗиденең сиксән сигез баскычы,*
Шәһри Болгар вәлиләре – ислам диненең ачкычы...»

Болгар, мөселман дөньясының йөзек кашы булып, тирә-юньгә биниһая иман нуры тараткан!

Әмма... Җилләр искән, комнар күчкән, мәһабәт йортлар вәйран кылынган. Аларның нигезе кайда? Аларны кайдан эзлисе?

Болгардагы Җәмигъ мәчетенең нигез ташлары исә гасырларны исән-имин кичә алды. Бүген без, кыйблага карап, шунда сәҗдә кылу бәхетенә ия.

2010 ел

1236 елдан соң ук башланган мәчет төзелеше XIII гасыр ахырында тәгамәлләнгән. Мәчет Алтын Урданың тәүге чорыннан сакланып калган архитектура корылмасыннан гыйбарәт.

Төзелеш материаллары һәм төзү алымнары буенча Җәмигъ мәчете Кавказ арты, Кырым, Кече Месопотамия корылмаларын хәтерләтә.

1989 ел

2019 ел

«ШӘҺРЕ БОЛГАРНЫҢ БӘГЪЗЕ АСАРЕ»

ТӨРЛЕ ГӨНАҺЛАРДАН ҺӘМ ЯВЫЗ КӨЧЛӘРДӘН САКЛАУЧЫ ИЗГЕ ДОГАЛАР, КОРЪӘННЕҢ ТӨРЛЕ СҮРӘЛӘРЕ ҺӘМ АЯТЬЛӘРЕ ЯЗЫЛГАН ШӘМАИЛЛӘР КҮПЧЕЛЕКНЕ ТӘШКИЛ ИТӘ.

Игътибарыгызга тәкъдим ителә торган шәмаилгә: *«Ошбу әшкялнең нәкыше Габделвәли вә борадәре Мөхәммәтгали бине Садыйк Әхмәтевләрнең иҗтиһадияләреннән улып һәм үз хәраҗәтләре (чыгымнары) илән Казанның университет матбагасында табгы улынды (басылды) 1902 нче сәнәдә»,* – дип язылган.

Шулай ук Болгар шәһәренең тарихы да бирелгән.

«Шәһре Болгарның бәгъзе (кайбер) асаре (әсәре).

Таварихе Болгариядән (Болгар тарихыннан) сабит (ышанычлы) булмаса да, бер хәбәр.

Пәйгамбәремез Мөхәммәт Мостафа с. г. в. Болгарга, ислам диненә дәгъвәт кылмак өчен, өч сәхабәсен күндерде.

Шөйлә (шулай итеп) риваять кылыныр ки: хәзрәти Гайсә галәйһиссәлам дөньяга килмәстән унбиш яки егерме ел мөкатдәм (элек) Искәндәр Зөлкарнәин (Александр Македонский) золмәткә (яулап алу өчен) күп гаскәр илән сәфәр кылды. Золмәттән кире кайттыкларында, Мәҗриасгар буенда гаскәренең күбесе татарлардан кыз алып кайттыклары сәбәпле, Буылга Иделе белән Кама Иделе кушылган җиргә җиткәч, Искәндәр Зөлкарнәиннең ун меңнән зиядәрәк (күбрәк) гаскәре татар кызлары алганлыктан, барчасының алмыш җәмәгатьләре, Буылга Иделене күреп, үзләренең ирләреннән бу дәрья буенда истикамәт (турылык, намуслылык) итүне арзу кылдылар (теләк белдерделәр). Бәс, ирләре Искәндәр Зөлкарнәиннән таләп кылып: «Әгәр әмер вә фәрман идәр исәңез, безләр, ошбу ике Идел кушылмыш урынның мәшрикъ (көнчыгыш) тарафында бер шәһәр корып, җәмәгатьләремез илән шунда истикамәт идәр идек», – диделәр. Искәндәр Зөлкарнәин, бунларның гарызларын (үтенечләрен) кабул итеп, имән агачыннан Болгар шәһәрен бина кылдырып, һәм бу шәһәрдә калгучы ун меңнән зиядәрәк (артыграк) гаскәргә, Буылга Иделе буенда калдыклары өчен, Буылгар диде. Имди бунларны (моңарга) Буылгар дию (дип) тәсмия ителгәч (исем кушкач), соңра шәһәргә һәм Болгар дип исем куйдылар. Әмма пәйгамбәремез Мөхәммәт Мостафа салаллаһу галәйһи вәссәлам Болгарга, ягъни ханына ислам диненә дәгъвәт кылмак өчен, үзенең өч сәхабәсен күндерде. Бу сәхабәләр, Болгарга килеп, ханны һәм барча халыкны дингә дәгъвәт кылдылар. Хан дәхи (янә) ханның җәмигъ (барча) халкы, бунларның дәгъвәтен кабул итеп, хак мөселман улдылар. Моннан соң бу әсхабе кәрәмнең (сәхабәнең) берсе Мәдинәгә кире китеп, әмма калмыш ике сәхабә, ягъни Чыгъдагази илән Зәбир Болгарда калып мәдфүннәр (шунда җирләнгәннәр) дигән сүзләр дә бар. Ләкин Иссыхкүл Мәэмүн хәлифә бине Һарун Әр-Рәшид Бәгдадтан Болгарга мәшһүр Ибне Фазланны берничә илче илән Болгар халкын дингә дәгъвәт кылмакка күндерде. Бәс мәзкүр (искә алынган) Ибне Фазлан, илчеләр илән Болгарга килеп, халыкны дингә дәгъвәт кылгач, хан һәм барча Болгар халкы, иман китереп, мөселман улдылар. Әмма Болгарда мәдфүн улынмыш (җирләнгән) әүлияләр күптер. Шул сәбәпле, Болгарга әтрафтан һәр заман зиярәткә мөселманнар бик күп киләләр. Болгар шәһәре һиҗрәи ел илән 800 елда хәрап булмыш. Әмма хәрап булуының сәбәбен белгән кеше юктыр, бәгъзеләр су баскан, бәгъзеләр (кайберәүләр) Аксак Тимер килеп хәрап кылмыш, диярләр. Ләкин хакыйкатен белгән кеше аслан (нигездә) юк. Хәзер дә Болгар шәһәре урынында ханнардан калмыш олуг таш манара илән берничә вәйран гыймарәтләре (җимерелгән биналар) бар һәм әүлияләр кабере күптер. Мәзкүр (әлеге) зур таш манара илән дәхи (тагын) берничә вәйран гыймарәтләре ошбунда нәкыш ителде (сурәтләнде)».

Журналга ***Рәйсә Шәрәфиева*** *әзерләде.*

Олы манара

Болгар

Шагыйрь Зөлфәтнең «Биеклек» шигырендә күкләргә иң якын таш турында уйланулар бар. Заманында Җәмигъ мәчетнең Олы манарасы да, һичшиксез, күккә иң якын таш булуны дәгъва итеп корылгандыр...

Олы манараның 1827 елгы күренеше. А.К.Шмидт рәсеме

Ф.Х.Эрдман рәсеме. 1825 ел

Петр Iнең борынгы Болгар истәлекләрен реставрацияләү һәм өйрәнү зарурлыгы турында указы барлыкка килү нәкъ менә шушы манарага бәйле. 1722 елгы Фарсы походы вакытында император Болгар хәрабәләрен шәхсән үзе караган, алар анда зур кызыксыну уяткан. 1722 елның 2 июлендә, Әстерхан шәһәренә җиткәч, император Казан губернаторы А.П.Салтыковка атап указ җибәргән. Ул анда «Казан губерниясендә борынгы Болгар шәһәрлегендә татар манаралары дип аталган ике баганаың нигезен төзәтүне» таләп иткән.

Олы манара төзекләндерелгән, ләкин безнең көннәргәчә сакланмаган, 1841 елда җимерелеп төшкән. Җимерелер алдыннан аны инглиз галиме Э.Турнерелли караган. Кече манарадан аермалы буларак, Олы манара ике тапкыр биегрәк булган һәм фасадының урта биеклегендә гарәп язмасы – Коръән сүзләре уелган.

Кара пулат

Болгар

Кара пулат – Болгар хәрабәләре арасында иң мәгълүме.

Җанкыяр Аксак Тимергә кәнизәк булуга караганда, ут эчендәге ошбу бина өстеннән сикереп, һәлак булуны артык күргән хан кызы турында риваять кемне генә тетрәндермәс?!

Бу риваять бүген дә халык күңелендә... Димәк, аның чынбарлык булмый чарасы юк.

Кара пулат – Алтын Урда чоры Болгарының (XIV гасыр) безнең көнгә кадәр иң тулы сакланган биналарыннан берсе. Ул туфтан һәм известьташтан төзелгән.

Григорий Григорьевич (1802-1865) һәм Никанор Григорьевич (1804-1879) Чернецовлар альбомыннан. 1838 ел

«Кара пулат» операсыннан күренеш. Либретто авторы – Ренат Харис, композитор – Эльмир Низамов. Төп рольләрдә – Гөлнара Гатина һәм Рузил Гатин. 2015 ел

ШӘҺРИ БОЛГАР *бәетләре*

* * *

Шәһри Болгар манарасы язулы икән башлары,
Шәһри Болгар мәчетендә бар да әүлия башлары.

Шәһри Болгарның кызлары киндер башмак кигәннәр,
Сабак укырга килгәндә җир астындин килгәннәр.

Шәһри Болгар юлларына таш пулатлар салалар,
Шәһри Болгар вәлиләре[1] *каршы чыгып алалар.*

Габдрахман коесындан дәвага су алалар.
Габдрахман тау башына нәзер корбан чалалар.

Габдрахман коесының төбе тирән, суы күп,
Габдрахман сәхабәнең исеме калган, үзе юк.

Рабига күлләренең әлиф кебек[2] *юллары.*
Шәһри Болгар вәлиләрнең күккә ашкан нурлары.

Рабига күлләренең әйләнәләре куак;
Җылый-җылый гамәл кылыйк, бу дөньяда без кунак.

Шәһри Болгарларга бардым зиярәт кылырмын, дип,
Рабига күлләрен күргәч, сәламәт булырмын, дип.



[1] Вәли – башлык, ия, изге кеше.
[2] Әлиф кебек – туры, төз мәгънәсендә.

* * *

Сәлам улсын сиңа, Болгар, олуг данлар күтәрдең,
Мәдәни шәһәр улдыгың Яурупага күстәрдең[1]*.*

Синең изге балаларың китапларын алдылар,
Наданлык вә җәһаләтне[2] *аяк аска салдылар.*

Тимердән вә ташлардан салган биналар вәйран,
Ни сәбәптән улды вәйран, гафилләр[3] *улыр хәйран.*



Болгар шәһәренең планы. А.К.Шмидт (1783-1843) альбомыннан. 1827 ел

Иске ташлар, тирән базлар ятыр анда бу заман,
Әгәр кайтып күрер булса, танымас иде аны хан.

Җиһанны тетрәтмеш иде синең олуг шәүкәтең[4]*,*
Кайда милкең, кайда гыйльмең, кайда бөек дәүләтең?

---

[1] Күстәрдең – күрсәттең.
[2] Җәһаләт – наданлык.
[3] Гафилләр – белмәүчеләр.
[4] Шәүкәт – көч, куәт, олылык.

Кече манара

Болгар

Шәһре Болгарга килгән туристларның яраткан урыны ул Кече манара.

Үзенең гүзәллеге белән мосафирларны хәйран иткән, иҗат әһелләренә илһам биргән, ташларына азан сеңгән тарихи ядкәр бу.

Кече манара – Болгарның иң яхшы сакланган архитектура истәлеге.



Ф.Х.Эрдман рәсеме. 1825 ел

«Болгар авылы. Кече манара һәм Ак пулат хәрабәләре». А.К.Саврасов (1830-1897). 1872-1874 еллар

XIV гасырның икенче яртысында төзелгән Кече манара 1712 елгы чыганакларда телгә алына. Ул 16 метр биеклектә. Аркалы ишеген һәм орнаментлы куышын таштан уеп ясалган нәфис бизәк матурлап тора. Бизәлеш эзләре өске галереяда да сакланган, аңа 40 баскычлы әйләнгеч таш баскыч алып менә. Бу манара, шәһәрлекнең үзәк өлешендә урнашкан манарадан тәбәнәгрәк булганы өчен, Кече дип аталган. Ул мөселманнар өчен аеруча изге урын санала.

Кече манара күренешләре. 1950 нче еллар

Сызлаулы хәтерне яңарту

Зиннур Мансуров

Күтәрелеп Кече манарага,
тарих төпкеленә төшкән бар.
...Эскәнҗәдәй кысып язмышларны,
идән булып иңгән түшәмнәр.
О, вандаллык гыйфрит кыяфәтле
ташваткычның үзен он иткән!
Болгарымның көле борынгыда
гөл булганын әллә оныткан?!
Чәрдәкләнеп беткән таштабакның
китегендә тере нур калган!
Оешмасмы җырлы тәлинкәгә?! –
Ярчыкларның кайсы янган,
кайсы урланган...
Вәхшилекне күрдем – культуралы
катлам читен бераз ачтым да.
...Каендагы карга оялары
һаман тора кояш астында...

Ханнар төрбәсе

Болгар

Борынгы бөеклегебез өчен ихлас рәхмәт әйтеп, баш орыр урыныбыз бу.

Кайда гына яшәмәсен, кемнән генә тумасын, һәр татар кешесенең шәҗәрәсе бирегә килеп тоташа...

Г.Г. һәм Н.Г.Чернецовлар альбомыннан. 1838 ел

Кече манарадан төньяк юнәлештә өч төрбәнең хәрабәсе сакланган, аларның берсе Ханнар төрбәсе дип атала. Ханнар төрбәсе – XIV-XV гасыр башындагы архитектура биналары комплексының бер өлеше, бу биналар көнчыгыштан көнбатышка таба бер сызыкта ята. Алар XVIII гасыр чыганакларыннан мәгълүм. Комплекс археологлар тарафыннан 1914 елда һәм 1968-1969 елларда тикшерелгән. Төрбәнең янкормасында мич һәм җылылыкны идән астыннан алып баручы каналлар табылган.

1950 нче еллар фотосы



Көнчыгыш төрбә

Болгар

Ташлар да авыр язмышка дучар булучан... Көнчыгыш төрбә – шуның ачык мисалы.

Хакимнәр ихтыярына каршы тора алмыйча (хәрәкәтсез таш бит ул!), әлеге күркәм бина үз гомерендә берничә мәртәбә тышчасын да, эчен-эчтәлеген дә алыштырырга мәҗбүр була. Ләкин асылын алыштырмый. Һәм, форсат туугач, язмыш аны кабат шул асылына кайтара...

А.К.Шмидт рәсеме. 1827 ел

Көнчыгыш төрбә XIV гасырның 30 нчы елларында төзелгән, затлы болгар нәселе – Борашбәкләрнең гаилә төрбәсе булган.

Ул корылышы буенча Урта Азия төрбәләренә, ә төзелеш материаллары, техник алымнар һәм деталь формасы буенча Кавказ арты һәм Кырым төрбәләренә охшаш.

XVIII гасыр башында корылма христиан храмы (Изге Никола чиркәве) буларак файдаланылган.

Төньяк төрбә

Болгар

Бу ташларда – тарих.
Ни генә кичерсәләр дә, алар беркемгә дә үч тотмый.
Барысы да уза, онытыла.
Ә ташлар онытмый...

Төньяк төрбә XIV гасырның 30 нчы елларында төзелгән, затлы болгар нәселенең гаилә төрбәсе булган. Ул Җәмигъ мәчете каршында урнашкан.

XVIII гасыр башында Успение монастыре монахлары аны баз итеп файдаланганнар.

Хәзер анда Алтын Урда чорының кабер ташлары күргәзмәсе эшли.

Төньяк төрбә.
XX гасыр
уртасы

2010 ел

Ак пулат

Болгар

Сәламәт тәндә – сәламәт рух.
Пакь тәндә – пакь җан.
Керсез күңел керсез гәүдәгә генә сыена ала.
Безнең бабайлар бу бөек хакыйкатьне борынгыдан белгән...

Г.Г. һәм Н.Г.Чернецовлар альбомыннан. 1838 ел

2010 ел

Ак пулат – XIV гасырның 40 нчы елларында салынган. Ул урта гасырларда Урта Азиядә, Кырымда, Кавказ артында киң таралган көнчыгыш мунчалары үрнәгендә төзелгән. Болгарларның төзелеш техникасы камиллеген һәм шәһәрнең чиста-пөхтә булуын дәлилләп торган.

Ак пулат – шәһәрдәге җәмәгать мунчаларының берсе, аның бай бизәлешле бинасы гөмбәзле үзәк залдан, киенү-чишенү бүлмәсеннән, юыну бүлмәләреннән һәм мич ягу өлешеннән гыйбарәт. Үзәк зал кайвакыт ял итү, әңгәмә кору һәм җыелыш җыю урыны булып та хезмәт иткән. Мунчада ванналы һәм фонтанлы аерым бүлмәләр дә корылган. Җылыту өчен мичләр, кайнар һава юллары, салкын һәм кайнар су белән тәэмин итү, юынтык суларны агызу системалары эшләгән. Болар барысы да алга киткән Көнчыгыш стандартларына туры килгән.

Ак пулат XIX гасырның 60 нчы елларында җимерелгән. Әмма аның XVIII гасырның икенче яртысында-XIX гасырның беренче яртысында ясалган күпсанлы рәсемнәре сакланган. XX гасыр ахыры-XXI гасыр башында шул рәсемнәр нигезендә тергезелгән.

Кол Гали кунакханәсенең СПА комплексы.
Ул XIV гасыр ядкәре – Ак пулат үрнәгендә төзелгән.



«Болгар күренеше». Француз рәссамы А.Дюран (1807-1867) альбомыннан. 1838 ел



Болгарның гомуми күренеше. Ф.Х.Эрдман рәсеме. 1820 ел

БОЛГАРДАНМЫ КИЛӘСЕЗ?

Болгар-Биләр диясез,
Болгарданмы киләсез?
Болгар елкыларын һәйдәп,
Һинд илләрен гизәсез.

Җүкә ләнгәс – кәрәз балга,*
Җамаяклар – ачы балга,
Энҗе-мәрҗән, гәүһәр-якут
Агыла шәһри Болгарга.

***Зәйнәп Максутова** архивыннан*

*Ләнгәс – кәрәзле бал.

«Ак пулат». Г.Г. һәм Н.Г.Чернецовлар альбомыннан. 1838 ел

«Ак пулат». Г.Г. һәм Н.Г.Чернецовлар альбомыннан. 1838 ел

Хан сарае

Болгар

Биредә ханнар сарай корган.
Биредә алар дәүләт дилбегәсен учларында нык кысып тоткан.
Биредә алар ил-көнгә озын гомер, бәрәкәтле тормыш, котлы һәм бай киләчәк юраган.
Биредә бүген без басып торабыз...

2010 ел

Хан сарае XIII гасыр уртасында төзелгән. Ул манаралы кирпеч-таш корылмадан гыйбарәт. Әлеге урында археологлар 1994 елдан казу эшләре алып барганнар. Бу объектның 1227 елдан Алтын Урда хакиме, Җүчи улы, Чыңгыз хан оныгы булган Батый хан (1208-1255) сарае комплексына керүен раслый торган дәлилләр табылган. 2010 елдан башлап казу эшләре җанланды, сарайның нигезе тулысынча ачылды һәм реставрацияләнде. Өстенә саклагыч корылма куелды.

Бүгенге көндә бу ядкәрнең биләмәсе – ачык музей киңлеге, анда төрле артефактлар күрсәтелә.

Көнчыгыш пулат

Болгар

Көнчыгыш пулат Алтын Урда чорында корыла.

Шактый күп гомер узып, 1990 нчы еллар ахыры җиткәч кенә, ул, ниһаять, тәүге мәртәбә яңартылып ала. «Яңарыш» фондының 2010-2012 еллардагы эшчәнлеге нәтиҗәсендә бүгенге халәтенә керә.

2010 ел

Көнчыгыш пулатны Хан мунчасы дип тә йөртәләр. Ул XIII гасырның 90 нчы елларында кирпечтән һәм таштан төзелгән, Болгарның җәмәгать мунчасы булган. Шунысы кызыклы, бинаның көнчыгыш ягында мунчага су кертү өчен махсус сулык ясалган булган.

Тулаем алганда, ул Кызыл пулат, аеруча Ак пулат конструкциясен хәтерләтә.



Чүлмәк яндыру мичләре

Болгар

Болгар илендә чүлмәкчеләр бик югары сыйфатлы һәм күптөрле савытлар җитештергәннәр. Алар арасында аш-су пешерергә җайлаштырылган казан һәм 3-5 литрлы, артык зур булмаган чүлмәкләр, пешкән ризыкны салып өстәлгә куя торган тәлинкәләр, җамаяклар, кувшиннар һәм башка төрле аш савытлары, ашамлык һәм эчемлекләрне (он-ярма, ит-май, сөт) саклау өчен махсус ясалган хум, 20-30 литр сыйдырышлы чүлмәкләр, һәр гаиләдә кулланыла торган яктырткыч лампалар бар. Бала арбалары, бишек төпләренә урнаштырыла торган «стаканга охшаш туваклар» («бала чүлмәкләре»), кара һәм төсле металлургиядә кирәкле терекөмеш саклау өчен махсуслаштырылган сфероконуслар еш табыла.

Бу савытларны елга комы кушып изелгән кызыл балчыктан чүлмәк түгәрәкләрендә ясаганнар, бераз кояшта киптереп алганнан соң, махсус таякчыклар белән шомартып-ялтыратып алганнар; гади генә, әмма бик зәвыклы итеп дулкынсыман бизәкләр төшергәннәр, аннан соң кайнарлыгы 700-800 градуска җитә торган махсус мичләрдә (горннарда) яхшылап яндырганнар.

Практик яктан чыдам һәм формасы белән бик матур булгангадыр күрәсең, болгар чүлмәкчеләре җитештергән савытларны сәүдәгәрләр күрше халыкларга, бигрәк тә рус кенәзлекләренә илтеп сата торган булганнар. Мәскәү, Суздаль, Муром, Владимир, Белоозеро, Ростов, Бөек Новгород, Түбән Новгород, Киев, Чернигов кебек шәһәрләрне казыганда, болгар чүлмәкләре еш табыла. Алай гына да түгел, Суздаль тирәсендә археологлар болгар чүлмәкчеләре эшләгән остаханә калдыкларына тап булдылар. Биредә ике яруслы түгәрәк горннар (аскы катта – утын ягып җылыту, өстә – әзер продукция яндыру камералары) сакланып калган. Диаметры һәм биеклеге икешәр метрга җитә торган әлеге мичләр монголларга кадәрге чорда бары тик болгарларда гына. Рус һөнәрчеләре чүлмәкләрне гади мичләрдә – учакларда яндырганнар, шуңа күрә алар җитештергән продукциянең сыйфаты түбән булган. Бары тик XIV йөздә генә, болгар чүлмәкчеләренең турыдан-туры йогынтысы астында, кайбер рус шәһәрләрендә, мәсәлән, Мәскәүдә кызыл балчык чүлмәкләр ясарга өйрәнгәннәр.

Болгар шәһәрләрен һәм авылларын казыганда табыла торган кызыл балчык керамиканы фәндә «гомумболгар керамикасы» дип атыйлар. Ул барлык керамик табылдыкларның якынча 94-95 процентын тәшкил итә.

Фаяз Хуҗин, *тарих фәннәре докторы*

Мозаик панно

Идел буе Болгар дәүләтенең 922 елда исламны дәүләт дине буларак кабул итүе хөрмәтенә истәлек билгесе

Болгар

2012 елның 21 маенда ачылган бу бина борынгы Болгар архитектурасы стилендә төзелгән. Биеклеге – 25 метр. Сигез кырлы. Зур, түгәрәк титанит гөмбәзле. Өстенә һилал куелган.

Гөмбәзле залны Коръән сүрәләренең классик каллиграфиясе бизәп тора. Аның авторы – хәттат (каллиграф) Рамил Насыйбуллин. Үзәк залда – дөньядагы иң зур Коръән китабы. Моны Гиннесснең рекордлар китабы да раслый. Буе – ике метр, иңе – метр ярым, авырлыгы – сигез йөз килограмм. Үзе асылташлар белән бизәлгән. Сәнгати яктан соклангыч итеп башкарылганга күрә, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы аны мәдәни хәзинә итеп таныды.

Зал диварына Әл-Мөкътәдир хәлифә илчелегенең Болгарга юл күрсәтүче харитасы эленгән. Аскы катта Коръән музее, картиналар галереясы урнашкан. Андагы мозаик панно 922 елда Болгар ханы Алмышның Багдад хәлифәсе илчеләре белән очрашу тантанасын һәм бабаларыбызның рәсми рәвештә Ислам динен кабул итү мизгелен тасвирлый.

Сиңа вәхи иңде күктән,
ул – Коръән...

А.С.Пушкин

Ак мәчет

Болгар

Күз явын алырлык әлеге мәһабәт ансамбль 2012 елда Изге Болгар җыенына җыелган киң җәмәгатьчелек катнашында ачылды. Ул үз эченә Ак мәчетне, мөфти хәзрәтләренең резиденциясен һәм мәдрәсәне сыендыра.

Мәчетнең гыйбадәт мәйданы – мусалла – 88 колоннадан торган арка белән әйләндереп алынган, үзәгендә фонтан корылган. Бу урыннан гаҗәеп манзара ачыла: әнә, офыкка барып тоташкан гүзәл табигать, әнә, борынгы Болгар казылмалары, әнә, иксез-чиксез күк…

Ак төс ниятләр сафлыгын белдерә, тыныч тормышка мәдхия җырлый. Мәйдан уртасына корылган көмеш күлдә Ак мәчет тулаем чагылып тора.

Ак мәчет комплексы ислам архитектурасының иң яхшы үрнәкләрен берләштерүче җыелма образ булып тора. Мәчет бинасы өч гөмбәз һәм 46,5 метрлы ике төз манарадан гыйбарәт. Төп гөмбәзнең диаметры – 10 метр. Ә мәчет эчендәге гөмбәзнең биеклеге – 17 метр. Аның барабанында төсле пыялалардан торган 16 тәрәзә урнаштырылган. Минтимер Шәймиев тәкъдиме белән, манаралары Мәдинә шәһәрендәге Пәйгамбәребез (с.г.в.) мәчете стилендә корылган.

Ак мәчет комплексы ислам архитектурасының иң яхшы үрнәкләрен берләштерүче җыелма образ булып тора.

Хакка шөкер, бу китабым тәмам булды,
Тәңрем миңа күп игелек бүләк кылды,
Аңласагыз, мин — Тәңремнең зәгыйфь колы,
Көйгә салып, төрле хикмәт яздым имди.

Кол Гали «Кыйссаи Йосыф»

Болгар цивилизациясе музее

Болгар

Болгар цивилизациясе музее борынгы Болгар дәүләтенең дөнья культурасы үсешендәге тарихи ролен ачып бирә. Экспозиция дүрт бүлектән тора.

«Борынгы Болгарны ачу» бүлегендә Болгар турында көнчыгыш, борынгы рус һәм урта гасыр Европа кулъязмаларындагы, шулай ук XIX-XX гасыр башында, совет чорында һәм хәзерге заманда Болгарның мәдәни мирасын өйрәнү, саклау тарихы турында мәгълүмат тупланган.

«Болгар цивилизациясенең башлангычы һәм үсеше» бүлеге болгарларның килеп чыгышы, аларның Кытайдан алып Көнбатыш Европага кадәр географик киңлектә тоткан урыны һәм роле турында сөйли.

«Борынгы Болгар» бүлеге Болгарны урта гасыр ислам шәһәр культурасы үрнәге буларак тәкъдим итә: аның ныгытмаларын, архитектурасын, һөнәрчелеген, сәүдә итү рәвешен, халыкара элемтәләрен һәм халкының антропологиясен күрсәтә.

«Болгарның табигате» бүлеге Болгар шәһәре һәм Идел буе Болгар дәүләтендәге табигать шартлары турында мәгълүмат бирә.

Икмәк музее

Болгар

Бу музей 2012 елның 21 маенда ачылды. Ул Татарстан туфрагында иген игү, икмәк пешерү кебек изге эшләрнең борынгы заманнардан алып хәзергәчә тарихын чагылдыра.

Бронза, борынгы тимер дәверләре, урта гасырга караган уникаль экспонатлар тәүге игенчеләр узган катлаулы юлны (агач көрәктән башлап сукага кадәр) күрсәтә.

Җил һәм су тегермәннәре, тегермәнче йорты, амбар, ындыр табагы, икмәк пешерү йорты, тимерче алачыгы, һөнәрче осталарның сәүдә рәтләре...

Монда килеп, һәр кеше үз кулы белән ипи пешерә ала...

ХЛЕБ - ВСЕМУ ГОЛОВА!

Сәхабәләргә һәйкәл

Болгар

Татар тарихчысы Хисаметдин ибне Шәрәфетдин Әл-Мөслиминең «Тәварихы Болгария» китабында 681 елда Болгар тәхетенә Айдар хан утыруы турындагы риваять бирелгән. Аның буенча, Мөхәммәт пәйгамбәр (с.г.в.) үзенең өч сәхабәсен – Габдрахман ибне Зөбәерне, Тәлка ибне Госманны, Зөбәер ибне Җәгъдәне, табиблар сыйфатында, Болгарга җибәргән. Зөбәер ибне Җәгъдә, пәйгамбәр (с.г.в.) биргән юл таягына таянып, бу җирдә тәүге тапкыр вәгазь сөйләгән. Унике елдан соң ике сәхабә Мәдинәгә кире кайткан. Ә Җәгъдә исә, хан кызы Туйбикәгә өйләнеп, Болгарда калган. Риваятьтә язылганча, ул соңыннан Ханнар төрбәсе төзелгән урында җирләнгән.

Сәхабә җирләнгән урында 2012 елның 18 июнендә (Изге Болгар җыены уздырылган көнне) сынчы һәм рәссам Рөстәм Габбасов проекты буенча эшләнгән Истәлек билгесе ачылды. Аңа чалма, юл таягы һәм каурый каләм белән кара савыты ясалган. Бу әйберләрне Мөхәммәт пәйгамбәр (с.г.в.) үз сәхабәләренә Ислам динен таратырга җибәргәндә тапшырган.

Изге урында Истәлек билгесе. Изге Болгар җыены. 2012 елның 18 июне

АЙДАР ХАН ҺӘМ СӘХАБӘЛӘР

(Риваять)

Болгар шәһәре элек бик зур булган, зур-зур кибетләр буеннан-буена тезелеп киткән. Аның башында Айдар хан дигән гайрәтле патша торган.

Айдар ханның егерме яшькә җиткән Туйбикә атлы кызы бар икән. Ул авырый икән.

Мөхәммәт пәйгамбәр (с.г.в.) өч сәхабәне янына чакырып алган. Аларның берсе – Тәлка, икенчесе – Җәгъдә, өченчесе – Габдрахман. Шуларга рәсүлулла таяк биргән, чалмасын салып биргән, кара савыты биргән:

– Менә Шәһри Болгар йортына юнәлегез, урамнарында йөрегез, без – табиблар-быз, диегез, – дигән.

Болар Болгар йортына килеп җитәләр, урамда йөри башлыйлар. Айдар ханның вәзире дә урамда йөри икән. Вәзир сәхабәләрне алып кайта сарайга. Хәзер утырта боларны. Шуннан патша керә. Айдар хан патша сорый болардан:

– Сез каян килдегез? – дип.

– Без Мәккә-Мәдинәдән им итү, дәва итү өчен килдек, – диләр алар.

– Менә минем егерме яшьлек кызым бар, авырый, шешеп-шешеп чыккан.

– Дәва бар, – диләр сәхабәләр, – хәзер каен себеркесе кирәк булыр.

– Ә-ә, каен себеркесе бездә күп, – ди патша.

– Юк, – диләр алар, – безнең таяктан үскән себерке кирәк.

Бер урынга таяк кадап куялар.

Габдрахман сәхабә намаз укып тора, таяк утырткан җирдән су чыга, күз алдында каен себеркесе үсә.

Айдар хан патша бу эшкә хәйран кала.

Себеркене бирәләр патшага.

Менә кызны хәммамга алып киләләр. Аны җәймә белән кәнизәкләре күтәреп керә. Кызлар чабындыралар, юындыралар.

Туйбикә үзе киенә.

– Мин, – ди, – үзем генә чыгам, – ди.

Аякка баса, тәмам терелә бу.

Кыз әнисенең бүлмәсенә керә. Әнисе бик аптырый, Айдар хан патша янына кереп китә, кызның терелүе турында хәбәр бирә.

Хәзер Айдар хан сәхабәләргә әйтә:

– Кызымны бирәм берегезгә, – ди.

Кызны коръәнхафиз Җәгъдәгә бирергә була.

Сәхабәләр Мөхәммәт пәйгамбәргә (с.г.в.) хат язалар. «Ал», – ди, пәйгамбәр (с.г.в.) әйтә.

Кызына да, атасына да:

– Иманга килегез, – диләр болар.

– Бөтен шәһәрне иманга китерәм, – ди патша.

Ул бөтен шәһәрне мөселман итә.

Туйбикә белән сәхабә Җәгъдә егерме биш ел бергә тора.

Ә теге тылсымлы таяк утырткан җирдән чыккан коены халык изге кое итеп саный, «Туйбикә коесы» дип йөртә. Аның суы бик чиста, бик тәмле була. Хәзер ул кое юк инде.

Болгарга зиярәткә килгән бабайдан Н.Ибраһимов язып алган.

Табиб йорты

Болгар

Болгар һәм Идел буе Болгар дәүләте борынгы чорларда фәннәр, атап әйткәндә, медицина, табигать белеме, фармакология, шулай ук әлеге тармакларга бәйле һөнәрләр үсеше үзәкләренең берсе булып торган.

Шуны истә тотып, 2012 елның 5 октябрендә Болгар шәһәрлеге үзәгендә Табиб йорты – Россиядә бердәнбер булган гарәп-мөселман медицинасы музее ачылды.

Экспозициянең төп темасы – Идел буе Болгар дәүләте табибы Таҗетдин Әл-Болгари хезмәтләре: «Әт-тирьяк әл-кабир» (Зур тирьяк), «Әл-әдвия әл-мофрад» (Бердәнбер дару) һәм «Мохтасар фи мәгърифә әл-әдвия» (Даруларны белү өчен кыска китап).

Бу кульязмаларның күчермәләре Иран белән Төркия музейлары, китапханәләре фондсаклагычларыннан кайтарылды.

Кара савыты. Балчык..
Каләмләр. Тимер. XIII - XIV гасырлар.
Чернильница. Поливная керамика.
Писала. Железо. XIII - XIV века.

Болгар табиб-фармокологларының хезмәтләре үз илләреннән читтә дә билгеле булган.

БОЛГАРЛАРДА МЕДИЦИНА

Борынгы заманнардан алып соңгы вакытка кадәр болгарларда дару – «ут» («үлән»), ә табиб «утчы» («травник») дип аталган. Андалусиядән Болгар иленә килгән Әбү Хәмид әл-Гарнати (XII гасыр) хан һәм аның хатыны авырып киткәч, «аларда кабул ителгән дарулар белән дәвалаулары» хакында яза. Салкын тиюдән терелү өчен бал куллану, бөердә һәм сидек куыгындагы ташларны бетерү өчен мүк җиләге (клест) белән тукланган кош ите кисәкләрен куллану Болгарда киң таралган.

Шулай ук елга кондызының мускуслы бизеннән алынган кыйммәтле дару да файдаланылган. Ул параличтан, кул һәм аяклар калтыраудан, хәтерне вакытлыча югалтудан, хатын-кыз авыруларыннан котылырга ярдәм иткән.

Төрле авырулардан биологик дару сыйфатында миллион еллар элек ташка әйләнгән диңгез моллюскларын – белемнитларны да файдаланганнар. Белемнитлар порошок рәвешендә кулланылган. Аны яңгыр суы белән катнаштырып эчкәннәр яки яраларга сипкәннәр.

Әфганстанда, Төньяк Һиндстанда, Иранның кайбер төбәкләрендә элек-электән тире авыруларын дәвалауда һәм, нигездә, авыр яраланган вакытта «чарме-и Болгар» («Болгар тиресе») мае кулланылган. Ул иске тирене яндырганда алынган көл нигезендә әзерләнгән. Шундый даруны көлгә яңа суйган хайванның сөяк җилеген кушып болгатып ясаганнар.

Археологик материаллар арасында хирургия инструментлары – ланцетлар, пинцетлар, махсус хирургия пычаклары очрый.

Авыруның кан тибешен искә алып, аның канын чыгарып дәвалау ысулы турында Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында да телгә алына. Болгар шәһәрләрендә

Авыруның канын чыгарып дәвалау ысулы турында Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында да телгә алына.

табылган үзенчәлекле пыяла савытлар – алембиклар (аламбеклар) дарулар ясаганда киң кулланылган. Алар ярдәмендә даруларны кирәкмәс кушылмалардан чистартканнар, шифалы парларны җыйганнар, саклаганнар.

Археологик истәлекләр арасында еш кына эре терлекнең өч өлешкә киселгән мөгезләре очрый. Бу тигез итеп киселгән куыш мөгезләр элегрәк, дәвалау чарасы буларак, татар халкында да кулланылган. Хәзер дә өлкәнрәк кешеләрдән «мөгез кую», «мөгез салу» гыйбарәләрен ишетеп була. Бу хәзерге заман медицинасындагы «банка кую», «банка салу» кебек бер үк мәгънәдә.

Болгарда медицина белемнәрен үстерүдә, шул вакытта фән өлкәсендә зур уңышларга ирешкән Көнчыгыш табиблары хезмәтләренең йогынтысы зур булган. Алар арасында XI гасыр башындагы иң зур галим Әбү-Гали ибне Синаны аерым билгеләп үтәргә кирәк.

Көнчыгыш медицинасы йогынтысында Болгарның үзендә дә профессиональ табиблар барлыкка килә. Болгар табиб-фармокологларының хезмәтләре үз илләреннән читтә дә билгеле булган. Борһанеддин Ибраһим Йосыф әл-Болгари «гади», ә Таҗеддин Юныс әл-Болгари «универсаль», катлаулы дарулар турында китаплар язганнар. Таҗеддин әл-Болгариның Мосул шәһәрендә (Гыйрак) язылган китабы безнең көннәргә кадәр килеп җиткән һәм ул 1997 елда Казанда нәшер ителде. Шулай ук Таҗеддин Юныс әл-Болгари да «патша һәм солтаннарның яраткан» сарай табибы булган.

XII гасырның беренче яртысында яшәгән тагын бер Болгар табибы Әхмәд Хуҗа әл-Болгари бөтен ислам дөньясында дан казанган. Болгардан Әфганстанга күчкәч, ул Газни шәһәрендә табиб була һәм танылган солтан Мәхмүд I Газнәвинең Бөек вәзире итеп билгеләнә. Шагыйрьләр аңа мәдхияләр язганнар.

Гамирҗан Дәүләтшин,
тарих фәннәре докторы

Төрки-татар язма мирасы күргәзмәсе

Болгар

«Татарлар арасында матбагачылык һәм мәктәпләр киң таралган, шуңа күрә татарлар барысы да укый-яза белә».

Миссионер П.Знаменский (1910)

Төрки-татар язмасы музее күргәзмәсе Идел ярында, ачык һавада урнашкан. Музейның экспонатлары – төрле заманнардагы төрки татар графикасында: рун, уйгыр, гарәп язуында, латин имласында һәм кириллицада хикмәтле әйтемнәр язылган стелалар. Биредә Кол Галинең, Тукайның, Мәрҗанинең сүзләре тәкъдим ителә.



Габдулла Тукайның «Милли моңнар» шигыре

Габдулла Тукайның «Пар ат» шигыре

Орхон-Енисей язмаларының күчермәсе



Муса Җәлилнең «Җырларым» шигыре

Габдрахман сәхабә коесы

Болгар

Сәхабә коесы яңартылгач, бередән кеше өзелми.

«Габдрахман кое каршында дәвә корбан чалалар ла,
Габдрахман кое суын дәва өчен алалар ла».

Шифалы сулы коедан ерак түгел корбан чалу белән бәйле йолаларны башкару өчен махсус урын булдырылган.

Татарлар чишмәне «Габдрахман сәхабә коесы» дип атыйлар һәм аның барлыкка килүен Болгар җиренә Мөхәммәт пәйгамбәр (с.г.в.) сәхабәләре килү белән бәйлиләр.

Риваять буенча, бу чишмәнең шифалы суы Габдрахман сәхабәнең юл таягы орынган урыннан ургып чыккан, әлеге су хан кызын савыктырырга булышкан. Кызының савыгу могҗизасын күреп, хан һәм аның иярченнәре ислам динен кабул иткән. Бу хакта Хәмит Әл-Гарнати язмаларында да искә алына. Сәяхәтче Идел буе Болгар дәүләтенә 1135 елда килгән, XI-XII гасырларда Болгар казые һәм тарихчысы булган Якуб ибне Әл-Болгариның китабын укыган.

Абдулла Алиш музее

Болгар

2018 елда Болгар җирлегендә күренекле татар язучысы, Муса Җәлилнең көрәштәш дусты Абдулла Алишка багышланган музей ачылды. Һәм бу һич кенә дә очраклы хәл түгел. Әдип шушы бәрәкәтле туфракта яралган.

1908 елның 16 сентябрендә Спас өязенең (хәзерге Спас районының) Көек авылында туган Абдулла Алиш 1944 елның 25 августында җәлилчеләр сафында һәлак була.

Музейда әдипнең кулъязмалары, үзе исән вакытта ук басылып чыккан китаплары, фоторәсемнәр һәм шәхси әйберләре урын алган.

Язучылар А.Алиш музее белән таныша. 2019 ел, июль

Елга вокзалы

Болгар

Теләсәк яшәргә, хаклы икәнлегебезне исбат итик;
Дәлилләр китереп, каршыларны сүздән туктатыйк.

Дөньяда болгарлар әле дә бар икәненә ышансыннар;
Якты бәхетебезгә көнләшсен һәм үзләре дә омтылсыннар.

Габдулла Тукай

Елга вокзалы Болгар цивилизациясе музее бинасының аскы катына урнашкан. Бинаның архитектура образы болгар мәдәнияте мотивларын чагылдыра. Елга вокзалының ике манарасы Идел буе Болгар дәүләтенең иң зур шәһәрләре – Сувар һәм Биләр образларын символлаштыра.

БОЛГАРГА КИЛГӘН ТУРИСТЛАР САНЫ



«

Узган ун ел безнең өчен кызыклы да, шул ук вакытта гаять катлаулы һәм җаваплы да чор булды. Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев җитәкчелегендәге «Яңарыш» фондының Болгар музей-тыюлыгы хезмәткәрләренә белдергән ышанычын акларга, аңа таяныч булырга, сынатмаска кирәк иде. «Яңарыш» фондының эш оештыру тәҗрибәсе безнең өчен һәрчак үрнәк булып торды. Без бик күп нәрсәгә өйрәндек һәм фонд ярдәмендә, аның белән бергә күркәм нәтиҗәләргә ирештек. Биредә музей-тыюлыкның элеккеге җитәкчеләре Рафаэль Мәхмутовның һәм Фәргат Мөхәммәтовның да өлеше зур дип саныйм.

Рамил Җиһаншин,
«Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» директоры:

Болгар тарих-археология комплексының ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелүе безгә зур бурычлар йөкләде. «Яңарыш» фонды Изге Болгар җирен югары дәрәҗәдәге дини, мәдәни, тарихи үзәк дәрәҗәсенә күтәрде. Төп бурычыбыз – шушы дәрәҗәне саклау, үстерү, тиңсез мирасыбызны төкми-чәчми киләчәк буыннарга җиткерү.

Бүген Болгар музей-тыюлыгында тормыш гөрләп-кайнап тора, дияр идем. Татарстанның һәм Россиянең барлык почмакларыннан, чит илләрдән кунаклар ел әйләнәсе өзелми. Шунысы куанычлы: укучы балалар, яшьләр Болгарга, бик теләп, елга берничә кат сәяхәт итәләр. Бездә бик күп милли, дини, мәдәни, мәгърифәти чаралар уздырыла. Аларның иң мәшһүрләре: «Изге Болгар җыены», балаларның «Милләт» уку һәм ял итү лагере, ЮНЕСКО Халыкара волонтерлар лагере, «Бөек Болгар» урта гасыр яулары халыкара фестивале, Халыкара археология мәктәбе, студентларның «Лига форум» белем лагере, шулай ук «Кыш батыр» кышкы спорт, «Болгар кунаклары» һәвәскәр халык иҗаты, «Иман моңы» халыкара музыка һәм «Чәк-чәй» ризык фестивальләре һ.б.

Хөрмәтле Минтимер Шәрипович! Хөрмәтле «Яңарыш» фонды хезмәткәрләре! Борынгы Болгар җирен торгызуга ярдәм иткән хәйриячеләр! Барыгызга да бик зур рәхмәт! Болгарга ешрак килегез! Сез – безнең иң кадерле кунакларыбыз!»



Изге Болгар җыены

Республикабызның Спас районында инде 30 ел дәвамында Изге Болгар җыены уздырылып килә.

1989 елда Идел буе һәм Урал алды мөселманнары, озак еллардан соң беренче тапкыр бирегә җыелып, ата-бабаларыбызның ислам дине кабул итүенең 1100 еллыгын билгеләп үтте. Шуннан бирле бу тантана ел саен үткәрелә башлады.

Изге Болгар җыенына республиканың һәм илебезнең төрле почмакларыннан меңнәрчә кунак килә. Борынгы дәүләтчелегебез булган урында намаз укыла һәм дога кылына.

Хәтер

Харрас Әюп

Безгә хәтер юкка бирелмәгән,
Яшәмәде халык хәтерсез;
Томаларга теләсә дә еллар,
Бәреп чыкты барыбер әйтер сүз.

Гөрләгән дә булды, дөрләгән дә –
Язып бара хәтер барын да.
Югалтырга безнең юк хакыбыз
Яманын да, яхшыларын да.

Мәкер өчен түгел безнең хәтер,
Зурaймыйдыр һичкем ут алып.
Бүгенгесен, үткәндәсен җуйса,
Киләчәктән мәхрүм ул халык...

Халык хәтереннән аерылганның
Яшәве дә әрәм, гел зая.
Азга гына килә җиргә кеше –
Хәтерләрдә гомер озая.

Яшералмас вакыт пәрдәләре,
Китсәннәр дә кире кайтырлар –
Безгә хәтер юкка бирелмәгән,
Югалмасын бары хәтерләр!..

Зөя утрау-каласы

Тарихи белешмә

Зөя (Свияга) һәм Идел елгалары кушылган урын – балыклы күлләргә, күпсанлы култыкларга, бай җирләргә игътибарны борынгыдан ук җәлеп иткән. Археология табылдыклары бу җирләргә кешеләрнең безнең эрага кадәр 4-6 меңенче елларда ук актив рәвештә урнаша башлауларын раслап тора. Соңрак әлеге җирләргә фин-угыр ыруглары күчеп килгән, ә Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чорында алар әлеге дәүләтләр кул астындагы биләмәләргә кергәннәр. Иделнең биек уң як ярындагы бу Түгәрәк тау ул заманнарда тугайлар арасында урнашкан, куе урман белән капланган, елъязма чыганакларына караганда, анда мәҗүси чирмеш ыругларының изге агачлыгы булган.

Свияжскиның – Зөя каласының төзелү тарихы гаҗәеп: 1550 елның кышында бу Түгәрәк таудан 800ләп чакрым ераклыкта, Углич янындагы ерак урманда, диварлары, манаралары, чиркәүләре һәм торак йортлары булган кала бурап куелган, ә 1551 елның язында, бураларны, сүтелгән килеш, Зөя елгасы тамагына агызып китергәннәр. Бары тик дүрт атна эчендә, дьяк Иван Выродков җитәкчелегендә, Мәскәү патшалыгының иң зур кальгасы калкып чыккан. Ул үлчәмнәре буенча шул замандагы Мәскәү, Псков яки Новгород кальгаларыннан зуррак булган. 1552 елда, Казан яулап алынгач, Зөя

Ташу вакытында Зөя шәһәренең көндезге күренеше.
А.И.Свечин һәм М.М.Махаев рәсеме буенча А.Г.Рудаков гравюрасы. 1769 ел.
ТР Милли музее фондыннан

каласы кыска гына вакыт әлеге төбәкнең хакимият үзәге ролен үтәгән. Соңыннан Иделнең уң як ярындагы кушылган җирләргә күзәтчелек иткән. XVI-XVIII гасырлардагы күпсанлы сугышларда катнашучы яугирләр сугышка биредән киткәннәр, шушы җиргә үк – бикерактагы Успение монастырена дәүләт җинаятьчеләрен һәм патша җәзасына эләгүчеләрне сөргәннәр. Зөя шәһәре иң югары икътисади үсешкә XVII-XVIII гасырларда – аның аркылы зур сәүдә юллары үткән чорда ирешкән. Губерна реформасы үткәрелгәннән соң, Зөя шәһәре бай Казан губернасының өяз үзәге булган.

XX гасырның иң фаҗигале вакыйгаларын – Беренче Бөтендөнья сугышын, Гражданнар сугышын, сәяси репрессияләр чорын, Бөек Ватан сугышын, СССР таркалгандагы болганчык елларны Зөя шәһәре бөтен ил белән бергәләп кичерә. Совет чорында утраудагы тарихи кыйммәткә объектларда җанкойгыч лагерьлар, төзәтү-хезмәт колониясе, республика психоневрология диспансеры филиалы урнаша, чиркәүләр, торак йортлар җимерек хәлгә килә.

Бәхеткә, «Яңарыш» фонды оешу нәтиҗәсендә, Зөя утрауда тормыш яңадан җанлана – архитектура истәлекләре реставрацияләнә, храмнарда гыйбадәт кылу башлана, яңа музейлар оештырыла, бирегә килүче туристлар саны елдан-ел арта.



Татар мәгърифәтчеләре

Зөя утрау-каласы турында

Халыкның риваяте буенча, Зөя өязендәге бәгъзе авыллар хакында берничә сүз сөйләмәстән элгәре, Зөянең үзенең кайсы вакытта салынганын бәян кыйлырга хаҗәт төште. Иң әүвәл башта Зөя каласын салган Иван Василич Грозный дигән патша, Казанны алмастан элгәре, 1551 елда.

Иван Василич Казанны килеп алмакчы булгач, үзенең ратникларына боерды: Казанга якын җирдә бер кала салырдай яхшы урын эзләргә. Ратниклар юлга чыктылар. Килеп бер җиргә туктадылар. Хәзер дә ул җирдә Исакау һәм Куҗамка дигән авыллар бар. Ул чагында Исакау белән Куҗамка арасында ике тау бар иде. Хәзер дә бар. Шул таулар өстенә кала кормакчы булдылар. Монда кала салсак, уңай булыр микән, дип, тагы яхшырак тикшереп карадылар. Әгәр дә анда кала салсалар, шул ике тау арасын дамба белән тутырып, ике тауны бергә кушарга кирәк буласы булды; хәзинәнең куәте җитәсе түгел, шуның өчен анда кала салуны мәслихәт күрмәделәр, янә аннан киттеләр; хәзердәге Зөя каласы урынына җиттеләр. Яхшылап тәмам тирәягын тикшереп, карап йөрделәр һәм, кала салырга бу урынны мәслихәт күреп, Иван Василичка әйтергә киттеләр.

Барып, Иван Василичка сөйләделәр. Әйттеләр, кала салырга бер мәслихәт урын таптык, бер тау өстендә бик һәйбәт урын бар, тауның бер ягында Зөя суы дигән елга ага, янә бер ягында бер елга бар, исемен белмәдек, ләкин щука балыклары бар, ул елга һәм байтак зур елга, икесе дә Иделгә коя, бик ерак бармый, диделәр. (Ул чагында Щука суы Зөядән ким түгел иде.)

Иван Василич:

– Инде алайса, ул елганың исеме Щука булсын, – диде һәм шул жиргә барып кала салырга боерды: – Ул каланың исеме һәм Зөя каласы булсын, – диде. Аннан соң Иван Василич боерды – Зөя тавының иң биек җиренә киндердән чиркәү ясадылар. Бу хәбәрне Казандагы татарлар ишетеп, бик куркыштылар. Урыс патшасы Казанны алырга килә икән, дип, гауга купты.

Зөя каласы хосусында моннан башка янә бер риваять бар, әмма бусы дөресрәккә охшый. Бәгъзеләр ошбу рәвешчә риваять кыйлалар: элгәре Зөя каласы урынында җимеш, йөзем, алмагач бакчасы булган. Иван Василич килеп, шул урынга кала сала башлагач күрде: Казан ерак түгел, ихтимал, Казан ханы бу эшне сизеп, эшебезне туктатыр, дип, әмер кыйлды: кала салганда Казан ханы күрмәсен, дип, Казан ягына зур киндердән чаршау кордылар. Алай булса да, бу хәйләнең файдасы озакка бармады. Казан ханы манара башыннан подзорный труба белән карап күрде: Зөя тавындагы бакчасында бер төрле галәмәт бар. Инде моны Казан ханы белсә дә, ни вакыйгалар булгандыр, һәрничек Зөя каласы – чаршау арты каласы – бар да бер, каланы салып тәмам иткәннәрдер.

***Каюм Насыйри**ның «Зөя өязе авыллары» исемле язмасыннан алынды.*



Зөя утрау-каласының 1829 елгы планы

Иван IV Казаннан 30-40 км көнбатышта, Зөя елгасының Идел дәрьясына койган җирендәге биек бер калкулыкта «Свияжск» исеме белән бер кала салырга карар бирә. Алдагы елның җәендә, бу ныгытма төзелгәч, Иделнең уң тарафында Мәскәү хакимияте тәмам урнаша һәм, шулай итеп, мәмләкәтнең яртысы тиз арада дошман кулына күчкән була. Нәкъ шул вакытларда Казанның үз эчендә дә тәртипсезлекләр хөкем сөргән. Азмы-күпме тотрыклы хөкүмәт тә булмаган. Казанлыларның ханы әлегә бишектә яткан Үтәмешгәрәй исемле бер бала булып, әнисе Сөембикә опекун саналган.

Свияжск каласы төзелеп бетәр-бетмәс, Мәскәү хөкүмәте казанлыларга өч бүлектән торган ультиматум куйган:

1. Тау ягында Мәскәү хакимиятен тану;

2. Бала хан белән опекун Сөембикәне Мәскәү хөкүмәтенә тапшыру;

3. Казандагы бөтен рус әсирләрен азат итү.

Ул вакыт эш башында торган Казан аксөякләре тарафыннан бу таләпләрнең һәммәсе барынча кабул ителгән һәм, нәтиҗәдә, Сөембикә белән улы Мәскәү воеводаларына тапшырылып, 1552 елның 18 августында Мәскәүгә китерелгәннәр.

***Габделбари Баттал**ның «Казан төркиләре» (1922-1923 ел, Хельсинки) исемле хезмәтеннән алынды.*

Җир астында – чал тарих

Зөя утрау

Зөя утрау-каласы археология мирасының уникаль объекты булып тора. Аның тарихи-мәдәни ландшафтының формалашуы борынгы заманнардан ук берөзлексез барган.

Утрау биләмәсен беренче үзләштерү Ананий археология культурасы чоры (безнең эрага кадәр VIII-V гасырлар) белән билгеләнә. Соңыннан бу биләмә яшәү өчен берничә тапкыр җайлаштырыла. Моны безнең эрага кадәр I меңьеллыкның беренче яртысына, II меңьеллыкның беренче яртысына караган казу урыннарында табылган әйберләр дәлилли. Әлеге табылдыклар бу җирнең төрле чорларда Зөя елгасы тамагын үзләштерүче кешеләрнең күңеленә ятышлы булганлыгын күрсәтә.

Бирегә актив төстә күченү Урта гасырлар чоры белән бәйле. Су юллары аша төбәкара һәм халыкара сәүдәнең үсеше елга буйларында авыл-шәһәрләр барлыкка килүгә этәргеч ясаган. Зөя елгасы тамагы, уңайлы сәүдә пункты буларак, үзенә тартып торган. Моны X-XI гасырларда Зөя янында барлыкка килгән болгар авыллары раслый. Шул чордан башлап бу территория актив рәвештә болгарлар тарафыннан үзләштерелгән.

Зөя каласы һәм аның посады территориясендә Болгар чоры (XI-XV гасырлар) табылдыклары булу шуны күрсәтә. 1551 елда – кальга төзү вакытында – калкулык һәм аның янындагы биләмәдә инде болгар-татар һәм Идел буе фин-угор халыклары яшәгән.

Успение монастыреның авырулар өчен палатасыннан фотограмметрия. 2014 ел

Туганнар каберлеге

Никола чиркәве янында казу эшләре. 2013 ел

Константин һәм Елена чиркәве янындагы каберлектә казу эшләре. 2016 ел

Татар бистәсе

Зөя утрау

XVI-XVIII гасырларда Зөя утравында татарлар яшәгән бистә булган. Биредә шактый уникаль – яр буендагы сулы туфрак астында озак гасырлар дәвамында 3 метр чамасы тирәнлектә «дымлы» мәдәни катлам формалашкан. Бу үзенчәлекле катламда органик әйберләр, шул исәптән, агач корылмалар, күн, тукыма, үсемлек җепселләре череми диярлек. «Дымлы» катлам 1978 елда археологлар Леонид Беляев һәм Лев Шавохин тикшеренүләре нәтиҗәсендә ачыкланган.

2011-2014 еллардагы казу эшләре вакытында бронза гасырга, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларына, шулай ук Зөя каласының XVI-XX гасырларына бәйле 140 меңнән артык археологик ядкәр табылды. Алар арасында металлургия, күн, агач, чүлмәк

120 см тирәнлектә археологик казу эше. 2012 ел

ясау, туку сәнәгате, балыкчылыкка мөнәсәбәтле предметлар, агач чаңгы, чана һәм хәтта бияләй дә бар. Шулай ук XI-XVIII гасырларга караган 79 корылма килеп чыга. Аларның 18е йорт булуы ачыкланды. Өйрәнелә торган биләмәдә ике урам һәм бер тыкрык урынын ачык шәйләргә мөмкин.

Археологик тикшеренүләр алып бару белән берлектә, табылган агач корылмаларны, органик материалларны саклау, консервацияләү һәм реставрацияләү эше дә башланды. Мәдәни катламнан алынган археологик табышлар бөтенләй башка физик-химик йогынтыга дучар ителә. Шуңа күрә дә әлеге музей проекты уникаль: яртылаш җир астында урнашкан, тәрәзәсез, тиешле шартлар тудырылган корылмада барысы да саклана.

Консервация һәм реставрация эшләре ТР ФАнең А.Х.Халиков исемендәге Археология институты һәм Дәүләт реставрация фәнни-тикшеренү институтының методик җитәкчелегендә башкарылды. Эшкәртелә торган археологик агачның күләме 60 куб метрдан, 3200 данәдән артып китте. 2015 елдан музей бинасын төзү эшләре башланды.

«Татар бистәсе» археологик агач музеенда Зөянең ничек үсеш алуын күзәтергә мөмкин. Биредә йортлар, киртәләр, ишегаллары, мичләр һәм коралларның нинди булганлыгын, кешеләрнең ни белән шөгыльләнүен күрәбез. Барлык объектлар да археологлар тапкан урында калдырылып, экспозицияләр формалаштырылды.

Музейның төп залы ике өлештән тора. Үзәктә археологик казылма урнашкан, әйләнә-тирәдә – экспозиция. 900 кв. метр мәйданда XVI гасыр уртасы-XVIII гасырдагы шәһәрнең агач корылмалары, ничек урнашкан булса, шулай чагылыш таба. Витриналарда өч бүлектән торган экспозиция урнашкан: урта гасыр агач төзелеше сәнгате; археологик артефактларның реставрациясе һәм консервациясе; XVI-XVII гасырларда Зөя каласында яшәүчеләрнең шөгыльләре һәм көнкүреше.

Музейның төп залына керүгә, 21 метрлы «Зөя каласы» анимацион панносын күрәбез. Экранда, тарихи чыганаклар нигезендә, XVII гасырдагы шәһәр тормышы реконструкцияләнгән. Биредә шәһәрне, аның табигатен, бала-чагаларның йөгереп йөрүеннән алып, балыкчы, балта осталарының эшләүләренә кадәр күрергә мөмкин.

Әлеге музей 2018 елның 5 сентябрендә ачылды. Аның гомуми мәйданы 2,5 мең кв. метрдан артык.

Археологик агач музее – Россиядә бердәнбер уникаль корылма. Мондый музей чит илләрдә – Швециянең башкаласы Стокгольм һәм Беларусьның Брест шәһәрендә генә бар.

Айрат Ситдыйков,
тарих фәннәре докторы

Троица чиркәве

Зөя утрау

Чиркәүнең бурасы 1550 елның кышында Углич урманнарында буралган. Бер көн эчендә төзелеп, 1551 елның 17 нче маенда – Изге Троица көнендә изгеләндерелгән.

Чиркәүнең XX гасыр башындагы фотосы

Чиркәүнең реставрациягә кадәрге фотосы. 2010 ел

Успение соборы

Зөя утрау

2017 елның 9 июлендә Успение соборы һәм монастыре – ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелде.

2011-2012 елларда соборның идән асты чүптән чистартылды, нигезе ныгытылды һәм гидроизоляцияләнде, бу исә гыйбадәтханәгә зыян китерүче җир асты суларыннан арынырга мөмкинлек бирде. Шулай ук бакыр түбә алмаштырылды.

Гыйбадәт йортының биләмәсе дә төзекләндерелде, сукмакларга, юлларга, мәйданчыкларга дискретлы катлам җәелде.

Успение соборы 1556 елда төзелгән.

XVIII гасырда өлешчә үзгәртеп корулар (трапезная, барабан, фасадлар, тәрәзә уемнары бизәлеше) бу соборның тышкы күренешенә барокко төсмере керткән. Эчке өлешендә XVI гасыр ахырына караган уникаль фрескалар җыелмасы сакланып калган, шул исәптән, иконография буенча бик сирәк очрый торган фреска – изге Христофор сурәте дә.

Успение монастыре

Зөя утрау

Богородица-Успение ирләр монастырена Зөя каласының үзе белән бер үк вакытта нигез салынган. Аңа яулап алган җирләрдәге халыкларны православие диненә тарту бурычын үтәргә тиешле миссионерлык үзәге вазыйфасы йөкләнгән, шуңа күрә Явыз Иван биргә ул чорның иң оста төзүчеләреннән Псков осталары Постник Яковлевны һәм Иван Ширяйны җибәргән. Алар, Мәскәүнең Кызыл

Төзекләндерү эшләре бара. 2010 ел

мәйданында әлегәчә Россия символларының берсе булып торучы Покров соборын (аны әле Василий Блаженный соборы дип тә атыйлар) төзеп, дан казанганнар. Зөя утравындагы Никола чиркәвен, Успение соборын шушы осталар торгызган. Бу храмнар бик озак вакыт Зөя каласының агач ныгытмасында бердәнбер таш корылмалар булган. Соңрак, XVIII-XX гасырларда, монастырьның территориясе киңәю сәбәпле, башка корылмалары да барлыкка килгән.

Никола Чудотворец чиркәве

Зөя утрау

Чиркәүнең 1894 елгы фотосы

Ул Зөя утрау-каласындагы иң борынгы урта гасыр чиркәүләренең берсе булып тора. Аңа 1555 елда нигез салынган һәм аны 1556 елның 6 декабрендә архимандрит Герман изгеләндергән. Гыйбадәт йортын ташчы оста Иван Ширяй һәм архитектор Постник Яковлев (Барма) җитәкчелегендәге Псков осталары артеле төзегән. Чиркәүнең эчке диварларына фрескалар ясалган булган, көнчыгыш фасадтагы Никола Можайский сурәте фрагментыннан башка берсе дә безнең көннәргә кадәр сакланмаган. Биредә изге Германның борынгы хөҗрәсе (келья) бар. Изге Герман җәсаденнән калган әгъзалар (мощи) 1922 елга кадәр Успение соборында кадерләп сакланган. Чиркәүгә XVII гасырда 43 метр биеклектәге дүрт катлы чиркәү манарасы тоташтырып төзелгән.

Зөя күренеше. Билгесез рәссам. XVIII гасыр уртасы

Татар мәгърифәтчеләре

Зөя утрау-каласы турында

Үзенең киңәшчесе Шаһгалинең мәслихәте белән, князь Иван кальга кору өчен шул тауның башында урын билгеләгән. Март 23ендә Мәскәүгә кайтып җиткәннәр. Икенче ел (1551 нчедә) яз башыннан ук князь Иван Касыймнан Шаһгалине чакырып, аның белән бергә биш йөз кадәр Казан мөһаҗирләрен вә күп воеводлар берлә куәтле гаскәрне Зөя кальгасен бина кылу өчен җибәргән. Аларга Казан вилайәтләрен сугышып алырга вә Казанга өзлексез һөҗүм итеп торырга әмер иткән. Кальга ихаталары вә бер кәнисә кыш көнендә үк Галич өязендә кисеп хәзерләп куелган; сулар ачылгач, алар Идел буенча Зөя суына кадәр зур көймәләр белән агызып төшереләчәк булган.

Руслар казанлыларның Идел вә Кама сулары аркылы йөртә торган көймәләрен (перевозларны) барын да үз кулларына алганнар.

1551 нче ел май 16сында кояш баеган вакытта русларның гаскәр башлыгы князь Серебряный Зөя тавының башына Русия әләмен (флагын) менгереп куйган. 18 нче майда Князь Серебряныйның гаскәре, төнлә Идел аркылы чыгып, иртә белән Казанга һөҗүм иткән. Бер меңнән артык йоклап ята торган мөселманны һәлак итеп, шулар арасында бер йөзгә кариб[1] князьләр вә морзалар да һәлак булган, имеш. Казанда әсир булып торган күп русларны коткарып, Зөя кальгасенә кире кайтып киткәннәр. Анда алар Русиядән зур гаскәр килеп җиткәнне көтеп торырга тиешле булганнар. Ул гаскәр, Зөя кальгасенә китереп куяр өчен кыш көнендә хәзерләнгән кальга ихатасы илә кәнисәне зур

[1] Кариб - якын

көймәләргә төяп, 24 нче майда килеп җиткән.[2]

Зөя тавында эре вә караңгы урман булган. Аны кисеп, Русиядән китерелгән кәнисәне вә кальга ихатасын оештырып куйганнар. Кальга ихатасына хәзерләгән агачлары яртысына гына җитәрлек булганлыктан, шул урындагы урманнан кисеп хәзерләп, бу кальганы дүрт атнада тәмам өлгерткәннәр. Әүвәлдә Мәскәү князенең исеме белән «Иван-город» исемендә куеп, соңыннан елга исеме белән «Свияжский» дип йөртелә башлаган.

Гайнетдин Әхмәров*ның*
«Казан тарихы» (1910)
исемле китабыннан алынды.

Иван Казанны 11 көн камап торса да, алырга хәленнән килмәде, һава көннән-көн җылынып, кечкенә елгаларда бозлар какшый башлады. Көн буе яуган яңгырлар белән аяк асты йөрмәстәй хәлгә килде. Болар барысы да Иван өчен эчпошыргыч нәрсәләр иде. Шуңа күрә февральнең 25 нче көнендә Казанны ташлап китте. Тупчыларның зур бүлегенә, олуг бүлек белән сакчы бүлеккә, шулай ук сул кулга үзенең алдыннан сәфәр итәргә боерды. Иван, Идел аркылы чыккач, Зөя суының тамагы янына туктады. Ул урында Түгәрәк тау аталган бер тау булып, Иван, янында 30 кеше булдыгы хәлдә, шул тауның башына менде. Аның башыннан тирә-якны күздән кичерергә тотынды. Бу тауның башына шәһәр бина итү сугыш ягыннан караганда, бик зур файдалы эш булып чыгачак идекен төшенеп, шунда бер кала бина итәргә уйлады. Анда шәһәр корылганда Казан йортына күп зарар китерергә, татарларга шактый тыгызлыклар кылырга мөмкин идекенә төшенде. Шәехгалине, шулай ук Иванга хезмәт итәр өчен Казаннан Мәскәүгә килгән татар бәкләре белән үзенең боярларын киңәшкә чакырып, шәһәрне кайсы урынга бина итәргә кирәклек хакында киңәшә башлады. Тегеләр барысы да Түгәрәк тау башына бина итү кирәклекне сөйләделәр. Иван үзе дә ул урынга шәһәр һәм чиркәү бина итүне муафикъ күрде[3].

Һади Атласи*ның «Казан ханлыгы» (1914)*
китабыннан алынды.

[2] Идел өстендә көймәләр белән Мәскәү гаскәренең башлыклары бу кемсәләр булган князьләр: Булгаков, Микулинский, Палицкий, Ногаев, падишаһ хатынының бөрадәре князь Юрьев, Мещера вилайәтеннән князь Хилков, Нижнийдан князь Серебряный, Оболенский, Вяткадан Бәхтияр Җүзин, алар белән мылтыкчылар вә казаклар да булган.
[3] Никоновская л., 5 т., 160 б.; Царственная кн., 461-462 б.; Татищев В.Н., 5 т., 277 б.

Сергий чиркәве

Зөя утрау

Сергий чиркәве (1570-1604 еллар) Борис Годунов заманында ук, биредә атаклы Троица-Сергий лаврасының йорты – Троица монастыре булган чорда ак таштан төзелгән. Ул Зөя утравының яклаучысы булып саналган Сергий Радонежскийга багышланган. Үз эченә гыйбадәтханәне, трапезная бүлмәсен һәм хуҗалык биналарын алган әлеге чиркәүнең төзелеше гаять кызыклы. Чиркәү ишеге янында «Троица Ветхозаветная» дигән борынгы фреска һәм храмны изгеләндерү вакыты күрсәтелгән язма сакланып калган.

2010 ел

Константин һәм Елена чиркәве

Зөя утрау

Храм XVII гасырда борынгы рус таш төзелеш сәнгате традицияләрендә, барокко элементларын файдаланып, XVI гасырдагы агач чиркәү урынына салынган. Зөя утрау-каласында сакланып калган бердәнбер приход чиркәве булып тора.

Фаразларның берсе буенча, чиркәүне Константин һәм Елена патшалар хөрмәтенә атауның сәбәбе Явыз Иван гаскәрләренең Зөя утравына изге Константин һәм Елена истәлеге көнендә килеп төшүендә булырга мөмкин. Өстәвенә, Явыз Иван Елена патшабикәнең улы булган.

2010 ел

«Барлык Кайгылылар Шатлыгы» соборы

Зөя утрау

1898-1906 елларда төзелгән, архитекторы – Ф.Н.Малиновский. 1914 елда Мәскәү фабриканты С.С.Мечников акчасына бизәлгән: собор эчендә майлы буяулар белән рәсемнәр ясалган. Төп престолның 4 катлы, үзенчәлекле иконостасы безнең көннәргә кадәр сакланган.

Казна корылмалары комплексы

Зөя утрау

XIX гасырда типовой проект буенча төзелгән бу комплекс гражданлык төзелеш сәнгатенең бик яхшы сакланган үрнәге булып тора.

Төзелгәннән соң анда казна конторалары, казначейство урнашкан, ишегалдындагы өч бинада төрмә булган. Совет чорында исә биналарның дүртесен дә НКВД төрмәсе иткәннәр.

Россиянең һәм Татарстанның бик күп күренекле мәдәният эшлеклеләре шушы төрмә аркылы узган.

Төрмә ябылгач, 2000 нче еллар башына кадәр бу биналарда республика коррекцион мәктәп-интернаты эшләгән.

XX гасыр буена бер тапкыр да капиталь ремонт үткәрелмәү сәбәпле, әлеге биналар реставрация алдыннан бик начар хәлдә иде.

SAMICK

Зөя утрау-каласы тарихы музее

Зөя утрау

«Казна корылмалары комплексы»нда хәзерге вакытта «Зөя утрау-каласы» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музее» урнашкан.

Төп бинада Зөягә нигез салыну, аның табигате, шәһәрнең беренче чорындагы үсешенә багышланган күргәзмә эшли. Шунда ук Зөя шәһәренең халкы, хакимият төзелмәсе, уку йортлары, чиркәүнең җир биләмәләре һәм хуҗалыгы турында сөйли торган экспонатлар да бар. Элеккеге төрмә бинасында XIX нчы гасыр азагындагы камера торгызылган. Күргәзмә Зөя өязе, тимер юллары, почта хезмәте һәм җирле медицина турында сөйли.

Музейда кызыклы очрашулар, фестивальләр, театр һәм музыка коллективлары чыгышлары, концертлар да оештырыла.



МУЗЕЙ ИСТОРИИ СВИЯЖСКА

«Әкият» балалар ял үзәге

Зөя утрау

Успение урамында күптән түгел генә төзекләндерелгән матур йортта балалар өчен интерактив күргәзмәле «Әкият» балалар ял үзәге урнашкан.

Бу үзәкнең бирердә булуы һич кенә дә очраклы түгел, чөнки бөек рус шагыйре А.С.Пушкинның «Солтан патша турында әкият»ендәге Буян утравы кайбер белгечләр хезмәтендә Зөя-утрауга тиңләштерелә.

Солтан патша турында әкият

(өзек)

Александр Пушкин

Кунаклар болай диләр:
«Без әйләндек күп илләр,
Тормыш начар түгел анда,
Мондый хикмәт бар дөньяда:
Бер утрау диңгездә
Очрый иде безгә;
Үзе текә, тар, кечкенә,
Яшәүче дә юк өстендә;
Буш тигезлек иде анда,
Тик бер имән үсә тауда;

Ә хәзер анда – яңа
Сарайлы матур кала;
Чиркәүләре алтын башлы,
Бакчалы зур йортлар яхшы.
Тора кала башында
Князь Гвидон анда.
Хөрмәт күрсәтте ул безгә
Һәм сәлам җибәрде Сезгә».
Бу хикмәткә шакката
Данлыклы Солтан патша.

***Шәйхи Маннур** тәрҗемәсе*

KAZAN

Гражданнар сугышы музее

Зөя утрау

Музей Зөядәге иң матур биналарның берсендә – XIX гасырның беренче яртысында мещан Медведевның классицизм стилендә төзелгән ике катлы йортында урнашкан. Җирле халык аны «колонналы йорт» дип тә атый.

1918 елда музей бинасында бишенче Кызыл Армия штабы урнашып, анда Совет Республикасының Революцион хәрби советы рәисе Лев Троцкий тукталган. Август-сентябрь айларында Зөя һәм аның тирә-ягы Россиядә Гражданнар сугышының беренче этабындагы хәлиткеч урын булып тора. Казанда урнашкан аклар (чех корпусы, Халык Армиясенең бер өлеше) һәм Иделнең уң як ярындагы кызыллар арасында канкойгыч сугышлар дәвам иткән. Казан белән Зөя арасында бер айлык көчле яу Кызыл Армиянең җиңүе белән тәмамлана.

Гражданнар сугышы музее 2016 елның маенда ачыла. Биредә 1918-1920 еллардагы «кызыллар» һәм «аклар» хәрәкәте тасвирланган. Октябрь революциясе юлбашчыларыннан берсе Лев Троцкийга аерым экспозиция багышланган.

КАРТА ПУТЕЙ СООБЩЕНІЯ РОССІЙСКОЙ ИМПЕРІИ
Россия Патшалыгының хәрәкәт итү юллары картасы
The route chart of Russian Empire

Сәяси репрессия корбаннары истәлегенә мемориал

Зөя утрау

Узган гасырның 20 нче елларыннан алып 1953 нче елга кадәр ГУЛАГның Зөя утравындагы филиалында 5 меңнән артык кеше тоткынлыкта булган. Бөек Ватан сугышыннан соң биредә төрмә генә түгел, ә сугыш инвалидлары һәм җәмгыятькә файдалы булмаган башка кешеләр өчен изолятор да урнаша.

Мемориаль зона утрау-каланы реставрацияләгәндә табылган 1940 нчы елларга нисбәтле каберлек урынында 2011 елда ачылган. Скульпторы – М.Гашимов.

Зөя-утрауда шагыйрь Хәсән Туфан да тоткынлыкта булган.

Хәсән Туфан
(1900-1981)



Бу – соңгы таңы аның

Сандугач сайрый тагын...
Ни була сайрамаса.
Ансыз да моңсу ласа,
Бу – соңгы таңы аның.
Сандугач сайрый тагын...

Ни була сайрамаса!..
Яңрата әрәмәне.
Япсана тәрәзәне:
Үзәкне өзә ләса.
Ни була сайрамаса...

Ансыз да моңсу аңа:
Бер аның җуела аңы,
Яңадан кайта тагы.
Сандугач, туктасана:
Болай да моңсу аңа.

Бу – соңгы таңы аның,
Нурлана бәйрәм кебек.
Күралмас бугай егет
Әнкәсен, туган ягын,
Бу – соңгы таңы аның.

Сандугач сайрый тагын...
«Кил, әни, элекке күк,
Йокысыз күземне үп,
Арала килеп җаным:
Сандугач сайрый тагын...»

1943

Ат утары биналары комплексы

Зөя утрау

Ат утары XVI гасырдагы агач утар урынына XVII-XVIII гасырларда кирпечтән төзелгән. Комплекста ат абзары, аран, лапас, ат караучылар өчен йорт булган. XX гасырда ул төзәтү-хезмәт колониясенең, аннан соң Свияжск психиатрия хастаханәсенең хуҗалык ишегалды функциясен үтәгән.

Каменев йорты

Зөя утрау

Шәһәрнең элеккеге башлыгы һәм хәйрияче сәүдәгәр Каменев йорты XIX гасыр ахырында төзелгән, утрауның төп – Раштуа мәйданында урнашкан. Совет чорында бинада икмәк пешерү йорты һәм кибет эшләгән, биредә яңа пешкән икмәк һәм азык-төлек сатканнар. Соңыннан бинаны торак иткәннәр. Кызганыч ки, 1990 нчы еллар азагында бинаны ремонтлау һәм тоту өчен акча җитмәү сәбәпле, ул тулысынча диярлек җимерелгән.

Комплекслы реставрациядән соң Каменев йортында шул исемдәге кунакханә ачылды, аның бүлмәләре бик уңайлы һәм зиннәтле, зур булмаган кафесы да бар.

Өе барның көе бар

Зөя утрау

2010 елда Зөядә вазгыять шулкадәр кискен иде ки, кешеләр ярымҗимерек монах хөҗрәләрендә, бернинди уңайлыклар да булмаган торакларда яши иде. Утрауны торгызу барышында биредә яшәүче халык өчен 3 шәхси һәм 19 күпфатирлы йорт төзелде.

Елга вокзалы

Зөя утрау

Елга вокзалы Зөя шәһәренең аскы өлешендә төзелде, аның составына касса, көтү залы, «Зөя утрау-каласы» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музее»ның туристлык-мәгълүмат үзәге һәм пассажирлар өчен зур булмаган кафе керә. Елга суднолары белән беррәттән, вокзал турист автобусларын да кабул итә.

ЗӨЯ УТРАУ-КАЛАСЫНА КИЛГӘН ТУРИСТЛАР САНЫ



«

«Яңарыш» фонды җитәкчелегендә башкарылган эш Зөягә яңа сулыш өрде. Әлбәттә, Зөя утрау-каласы язмышында катнашкан оешмаларга – «ТАИФ» ААҖ, «КАПО» ААҖ, Казан Компрессор заводы, «Сбербанк» ААҖ һәм башка инвесторларга зур рәхмәт.

Бүген Зөядә ЮНЕСКОның тотрыклы үсеш максатлары гамәлгә ашырыла. Музей-тыюлыкны туристлык үзәге буларак үстерү яңа эш урыннары булдыру, фәнни-тикшеренү, экологик һәм социаль эшчәнлек, реставрация чаралары, мәдәни мирас объектларының торышын даими мониторинглау белән бергә үрелеп бара. «Зөя утрау-каласы» музей-тыюлыгында ел саен берничә дистә күргәзмә үткәрелә. Аларда Россиянең эре музейлары катнаша. Илнең башка шәһәрләрендә Зөягә багышланган күргәзмәләр оештырылып килә. Зөя утрау-каласында ел саен үткәрелә торган чаралар Бөтенроссия вакыйгалар туризмы конкурсларында берничә тапкыр призлы урыннар яулады. Күп кенә кунакларыбыз «Зөя Масленицасы», «Музейлар төне», «Зөядә уха көне», «Зөя уклары», «Зөядә Яңа ел» кебек чараларда даими катнашып киләләр. «Зөя артеле» театр лабораториясе «Тере шәһәр» фонды белән берлектә үткәрелә. «Рудник» халыкара дебют документаль кино фестивалендә дистәләгән Россия һәм чит ил режиссер-документалистлары, аниматорлары катнаша. Фестиваль РФ Мәдәният министрлыгының рәсми кинофестивальләре исемлегенә кертелде. Билгеле, барлык бу уңай үзгәрешләр – «Яңарыш» фондының эш нәтиҗәсе. Татарстанлыларны, мөхтәрәм иганәчеләребезне һәм, әлбәттә, Минтимер Шәрип улы Шәймиев җитәкчелегендәге «Яңарыш» фонды хезмәткәрләрен юбилей белән котлыйм!»

Артём Силкин,
«Зөя утрау-каласы» музей-тыюлыгы директоры:

Гасырларны кичкән бәйрәмнәр



УКАЗ
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ

Болгар ислам академиясен төзү һәм

Казан Мәрьям Ана иконасы соборын торгызу турында

Традицион рухи кыйммәтләрне саклап калу һәм үстерү, конфессияара һәм милләтара тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту максатларында **карар бирәм**:

1. Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте, Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте үзәкләштерелгән мөселман дини оешмаларының Татарстан Республикасы Спас районы Болгар шәһәрендә «Болгар ислам академиясе» фәнни-мәгариф һәм дини-мәгърифәти мөселман үзәген (алга таба – Болгар ислам академиясе) төзү инициативасын хупларга.

2. Рус православие чиркәвенең Татарстан митрополиясе (Мәскәү Патриархаты) һәм Казан шәһәре Мәриясенен Казан Богородица монастыре комплексы эчендә Казан Мәрьям Ана иконасы соборын торгызу турындагы инициативасын хупларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

а) 2015 елның 31 декабренә кадәр Болгар ислам академиясен төзү һәм Казан Мәрьям Ана иконасы соборын торгызу буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга, шул исәптән түбәндәге урыннарда һәм көннәрдә истәлек ташлары куюу буенча чаралар оештыруны күздә тотарга:

Болгар ислам академиясен төзү урынында – 2016 елның 21 маенда, Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул иткән көнендә;

торгызылачак Казан Мәрьям Ана иконасы соборы урынында – 2016 елның 21 июлендә, Казан Мәрьям Ана иконасы табылган көндә;

б) әлеге проектларны гамәлгә ашыру өчен ирекле иганәләр җыюны, юридик һәм физик затлар, иҗтимагый һәм дини оешмаларның акча күчерүләрен оештыруга булышлык күрсәтү буенча чаралар комплексын эшләргә;

в) Болгар ислам академиясен төзүгә һәм Казан Мәрьям Ана иконасы соборын торгызуга өлеш керткән юридик һәм физик затлар истәлеген мәңгеләштерү максатларында истәлек китапларын гамәлгә кертүне һәм мемориаль билгеләр куюны күздә тотарга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 04 ноябрь
№ ПУ-1066

Болгар ислам академиясе

Болгар ислам академиясенең нигез ташына истәлек капсуласы салу. 2016 елның 21 мае

2017 елның 4 сентябрендә Болгар ислам академиясендә беренче уку елы башланды

Академия үз алдына Россия Федерациясе территориясендә дини белем бирү системасын, мөселман дин гыйлеме мәктәбен торгызу һәм үстерү, исламдагы традицион юнәлешләрне ныгыту, абруйлы галимнәрне берләштерү максатын куя.

Изге Болгар җыенында республика җитәкчелегенең дин әһелләре белән очрашу-киңәшүе күркәм гадәткә әйләнде

Болгар ислам академиясен ачу тантанасы. 2017 елның 4 сентябре



Болгар ислам академиясендә Попечительләр советы утырышы. 2020 елның 8 феврале

Казан Мәрьям ана иконасы соборы

Казан Мәрьям ана иконасы соборының XX гасыр башындагы фотосы

Соборны торгызу эшләре башланган мәл. 2016 ел, май ае

Мәскәү һәм Бөтен Русь Патриархы Кирилл катнашында Казан Мәрьям ана иконасы соборы нигезенә истәлек капсуласы салу тантанасы.
2016 елның 21 июле

Казан һәм Татарстан митрополиты Феофан, ТР Дәүләт Киңәшчесе М.Ш.Шәймиев, «Яңарыш» фондының башкарма директоры Т.П.Ларионова собор төзелеше белән таныша

Казан Мәрьям ана иконасы соборы тиздән дин тотучыларны һәм туристларны үзенә җәлеп итә торган изге урынга, башкалабыздагы мәдәни җәүһәрләрнең берсенә әвереләчәк

Ихлас күңелдән

«Кәгазь өстендә калган исем – бетмәс гомердер».
Ризаэддин Фәхреддин

«Яңарыш» фондына ярдәм иткән оешмаларның һәм аерым кешеләрнең исемнәре «Хәйриячеләр китабы»на язылып бара. Күпме иганә итүенә карамастан, изге эшкә катнашкан һәркем турындагы мәгълүмат тарихта кала.

«Хәйриячеләр китабы»ның 10 томы басылып чыкты. Аларда 78 мең хәйрияченең исеме урын алды. Иганәчеләрнең күбесе өч, дүрт, биш, ә кайберләре һәр томга да керде.

- I том – 5 мең, 2010
- II том – 10 мең, 2011
- III том – 7 мең, 2012
- IV том – 8 мең, 2013
- V том - 8 мең, 2014
- VI том – 10 мең, 2015
- VII том – 20 мең, 2016
- VIII том – 6 мең, 2017
- IX том – 3 мең, 2018
- X том – 1 мең, 2019

Иганәче Нугаевлар гаиләсе. 2012 ел

Камил НУГАЕВ,
ТР Дәүләт Советы депутаты, 2006-2019 елларда Спас муниципаль районы башлыгы:

«Кечкенәдән Болгар турында ишетеп үссәм дә, борынгы шәһәрлек белән соңрак таныштым. Тик эшемнең әлеге ядкәрләргә бернинди катнашы юк иде. 2010 елда гына, Болгарда Минтимер Шәрип улы эшли башлагач, мин боларның кызыклы һәм гадәти түгеллеген аңладым. Моның өчен аңа зур рәхмәт!

Борынгы Болгар һәм Зөя утрау-каласын төзекләндерү Татарстанда яшәүче һәрберебезнең изге бурычына әйләнде. Хәйриячелек эшенә хатыным Мәйсәрәне, улларым һәм оныкларымны да җәлеп иттем».

Наил МАГАНОВ,
«Татнефть» генераль директоры:

«Идел буеның гәүһәрләре булган борынгы Болгар һәм Зөя утрау-шәһәре – дәүләт һәм эшмәкәрлек, дини оешмалар, киң җәмәгатьчелек көче белән торгызылган кыйммәтле тарихи һәйкәлләр.

Татарстанның мәдәни кыйммәтләрен саклауда һәм үстерүдә «Яңарыш» фондының һәм аның Попечительләр советы рәисе Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең өлеше бәяләп бетергесез. Ул заман сулышын тоя белә, күпмилләтле республикабыз халкының мәдәни мирасын торгызуга һәм үстерүгә этәрүче ярдәмен күрсәтә.

Дөньякүләм әһәмияткә ия булган бу һәйкәлләрне торгызуда катнашу һәм әлеге игелекле эшкә мөмкин кадәр өлеш кертү – «Татнефть» өчен зур горурлык һәм намус эше. Безнең өчен мәдәниятебезне саклау, рухи кыйммәтләрне үстерү, балаларыбыз һәм оныкларыбыз үз халкының, иленең тарихы белән горурланырлык итеп киләчәк буыннарга тапшыру зур әһәмияткә ия».

Альберт ШИҺАБЕТДИНОВ,
1995-2019 елларда «ТАИФ» АҖ генераль директоры:

«Тарихның тиңсез байлыгына орынып, тарих-архитектура ядкәрләрен торгызуга үз өлешебезне кертү безнең өчен гаҗәеп мөмкинлек булды».

Радик ХӘСӘНОВ,
«Серго исемендәге завод» (POZIS) АҖ генераль директоры:

«Болгар һәм Зөя – ул туган ягыбызның, күпмилләтле Татарстан Республикасының тарихы. 2010 елда «Яңарыш» фондына нигез салган беренче Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев, әлеге миссиягә эшкуарларны, республикабыз халкын гына түгел, ә Россиядә һәм күп кенә чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызны да җәлеп итеп, бик игелекле эшкә алынды.

Бу елларда Зөя җирлегендә булган үзгәрешләр искиткеч! «Яңарыш» фонды тарафыннан биредә яшәүчеләрнең күп кенә социаль проблемалары хәл ителде.

Болгар каласы турында сөйләгәндә, безнең мөселманнар өчен ул – изге шәһәр, дип билгеләп үтәсем килә. Биредә динебез – ата-бабаларыбыз диненең тарихы башлана».

Марат НАГУМАНОВ,
«Пакер» фәнни-җитештерү фирмасы генераль директоры:

«Шәхсән үзем һәм «Пакер» фәнни-җитештерү фирмасы исеменнән «Яңарыш» фондын, аның хезмәт коллективын һәм барлык хәйриячеләрен әлеге фонд оешуга ун ел тулу белән ихлас котлыйм! Мәдәниятне һәм рухи кыйммәтләрне тергезү юлында бихисап игелекле гамәлләр башкарган Татарстан халкын да шул уңайдан тәбрик итәм.

Минтимер Шәрипович, һәр эшкә җитди каравы, зирәклеге һәм алдан күрүчәнлеге белән, хәйриячелекне эшмәкәрлекнең иң мөһим бурыч-вазыйфасы дәрәҗәсенә җиткерә алды, республикабызда һәм аннан читтә яшәгән байтак кешеләр өчен ерак-карак һәм тирәнгәрәк карарга өйрәтүче Остаз булды, яхшылыкка омтылуны, ата-бабаларыбызның рухын һәм киләчәк буыннарыбызның гүзәл язмышын кайгыртуны өлге итеп күтәрде.

Уңышлар һәм яңадан-яңа казанышлар телим!»

«...Дәүләтнең, сәнәгать предприятиеләренең, эшмәкәрлекнең һәм җәмәгатьчелекнең «Мәдәни мирас: борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя утрау-каласы» дигән зур уртак проекты нигездә тәмамланды. Һәм моның белән барыбызны да котлыйм!

Бу бик кызыклы һәм иҗади тәҗрибә, ачышлар һәм яңа фикерләр туу еллары булды, мин моны үз-үзебезне танып белү процессы, җәмгыятьнең рухи яңарышы вакыты дип атар идем.

Тарихи ядкәрләрне, архитектура ансамбльләрен торгызу, яңа әһәмиятле корылмалар төзү, заманча инфраструктура булдыру, бу җирлекләр биләмәләрен төзекләндерү белән беррәттән, иң мөһиме – рухи образларны: ата-бабаларыбыз иманын, традицияләрен һәм мәдәниятен тергезүгә ирешә алдык.

Шунысы аеруча куанычлы: беренче чиратта иң яхшы тарихчылардан, археологлардан, реставраторлардан, проектчылардан, төзүчеләрдән, киңәшчеләрдән торган һөнәри команда булдыра, ысулларын таба, технологияләр билгели алдык, шуның нәтиҗәсендә без бүген борынгы ядкәрләрнең чын кыяфәтен, бөеклеген һәм матурлыгын күрә алабыз.

2014 елда Болгар тарих-археология комплексының, ә 2017 елда Зөя утрау-каласындагы Успение соборы һәм монастыреның

ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелүе уртак эшебез нәтиҗәләренең халыкара дәрәҗәдә танылуын күрсәтеп тора.

Тарихи хәтерне саклау, аны киләчәк буыннарга тапшыру – республиканың хәзерге заман иҗади тормышында төп өстенлекләрнең берсе. Бу Россия Федерациясе һәм безнең республика җитәкчелеге иң югары дәрәҗәдә үткәрә торган уртак илкүләм бурыч булып тора.

Үз ана телебезгә, үз халкыбызга мәхәббәттән башка, бөек илебезне торгызып булмый.

Тарихны тергезгәндә безнең барыбызны да, һичшиксез, киләчәк буын – бүген мәктәп парталары артында утыручылар борчый. Туган йортка, авылга, шәһәргә, үзебез яши торган илгә карата ихтирам хисеннән, үз ана телебезгә, үз халкыбызга мәхәббәттән башка, бөек илебезне торгызып булмый.

Нәкъ менә шуның өчен, Болгар һәм Зөя утрау-каласын торгызу буенча эшне тәмамлап, «Яңарыш» фонды, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән бергә, уникаль мәгариф проектын – күп профильле мәктәптән, балалар бакчасыннан, интернаттан, шәһәр читендә балалар лагереннан торган гомуми белем бирү комплексын төзүне һәм оештыруны башларга ниятли. Ул академия белеме, өч телдә (рус, татар һәм инглиз телләрендә) әзерлек нигезендә, гомумкешелек кыйммәтләре, тигез карашлы тормыш фәлсәфәсе һәм кешелеклелек юнәлешендә тәрбияләнүче күпкырлы шәхес формалаштырырга мөмкинлек бирәчәк.

Яңа мәктәпкә рус, татар һәм инглиз телләрендә көндәшлеккә сәләтле белем бирүне тәэмин итү, мәгарифнең нәтиҗәле гамәли ысулларын куллану, укучылары үз мәдәниятен бәяли, башка мәдәниятләрне аңлый һәм җәмгыятебез үсешенә лаеклы өлеш кертә ала торган белем йорты булу вазыйфасы йөкләнә.

Күренекле фикер иясе, татар мәгърифәтчесе Шиһабетдин Мәрҗани бик төгәл әйткән: *«Үткәнен белмәгән, милли тәрбия алмаган кешенең киләчәге юк»*.

Игелекле эшләрегез өчен барыгызга да тагын бер кат рәхмәт белдерергә һәм эшегездә, тормышыгызда иминлек теләргә рөхсәт итегез. Барыгызга да исәнлек-саулык, иминлек телим!»

Минтимер Шәймиев,
Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе,
Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу
Республика фонды Попечительләр Советы Рәисе,
ЮНЕСКОның мәдәниятара диалог буенча Махсус илчесе

(«Мәдәни мирас: борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя утрау-каласы» комплекслы проектын гамәлгә ашыруны йомгаклауга багышланган тантанадагы чыгышыннан. 2019 елның 1 феврале)

Адымнар

2019-2022 ЕЛЛАРДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА

күп телдә белем бирүче 6 комплекс төзү проекты гамәлгә ашырылачак

Кил, өйрән, и туган, бер башка телне,
Бүтән телләр белү – яхшы һөнәрдер.
Катыштырма вә ләкин телгә телне,
Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер.

Дәрдемәнд



Әлегә төзелеш эшләре бара...

«Кеше капиталы – бу иң мөһиме. Татарстан икътисадының конкурентлыкка сәләте нәкъ менә шуңа нигезләнә. Балалар бакчалары һәм мәктәпләрне берләштереп, кимендә өч телдә – рус, татар һәм инглиз телләрендә белем бирүче хәзерге заман комплексларының вазыйфасы – республикабызның киләчәген формалаштыру. Мондый белем бирү комплекслары Казанда гына түгел, республиканың башка шәһәрләрендә дә ачылуы мөһим. Бу эшкә нәкъ менә Минтимер Шәрип улының һәм «Яңарыш» фондының алынуы куанычлы хәл. Аның гаять бай тормыш тәҗрибәсе, югары абруе, бу проектка бирелгәнлеге, фонд хезмәткәрләренең зур проектлар гамәлләштерү буенча тәҗрибәсе – болар барысы да бу гамәлнең уңышына эшләячәк».

Р.Н.МИҢНЕХАНОВ,
Татарстан Республикасы Президенты
2019 елның 1 феврале

«Хәрәкәттә – бәрәкәт» дип юкка гына әйтмибез. Хәрәкәт итмичә, бернигә дә ирешеп булмый. Без юлга чыктык, шуңа күрә программаны «Адымнар» дип атадык. Бу адымнар алга таба киң колачлы хәрәкәткә әвереләчәк...»

М.Ш.ШӘЙМИЕВ,
Татарстан Республикасының Дәүләт Киңәшчесе

Болгар һәм Зөя –
балалар иҗатында



ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
www.beznenmiras.ru

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- ***uslugi.tatarstan.ru*** сайты ярдәмендә
- редакциядә
- ***podpiska.pochta.ru*** сайты ярдәмендә электрон версия

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.